Кояш Тимбикова
Карахмат
мажаралары

Кояш Тимбикова

Карахмәт маҗаралары

ХИКӘЯЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1989

ББК 84 (2Р — Тат)-5
Т 45

ЭЧТӘЛЕК

Карахмәт мажаралары . 3
Бану әби сабагы . . . 27
Сагыну 38
Гарәп теле өйрәнгәндә . 46
Ачуланмасагыз? 50

Тимбикова Кояш

Т 45 Карахмәт мажаралары: Хикәяләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 56 бит. ISBN 5—298—00161—0

Т $\frac{4803010200-128}{М\ 132(03)-89}$ 185—89 ББК84(2Р — Тат)-5

Художнигы *В. Булатов*

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Тимбикова Кояш Закировна

ПРОДЕЛКИ КАРАХМЕТА

рассказы

(на татарском языке)

ИБ № 5297

Редакторы **М. Фәйзуллина.** Художестио редакторы **Ф. Хәсьянова.** Техник редакторы **Ф. Абдрахманова.** Корректоры **М. Кәримова.**

Жыярга тапшырылды 23.12.88. Басарга кул куелды 22.03.89. Форматы 70×90¹/₁₆. Типогр. кәгазе № 1. Гарнитура «Литературная». Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 4,1. Шартлы буяу-оттиск 5,27. Нәшер-хисап табагы 2,74. Тиражы 30 000 экз. Заказ А-543. Бәясе 15 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084, Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN 5—298—00161—0

© Татарстан китап нәшрияты, 1989

КАРАХМӘТ МАҖАРАЛАРЫ

Алдашмаска өйрәнгәндә

Гөлнурның, берәү генә калды инде, дигән сүзләрен ишетүгә, мин өйгә чаптым. Ишектән керә-керешли үк инәлә башладым:

— Әби-и, алып кайтыйм инде! Хәзер үк барып җитмәсәм, соңгысын да биреп җибәрәләр...

Әбием, һәрвакыттагыча, сузып-сузып сөйли башлады:

— Әүвәл чишен, каршыма килеп утыр, исән-сау тордыңмы, әби, диген. Аннары мәктәптәниләр булганын, ничәлеләр алганыңны сөйлә. Соңыннан гозереңне әйтерсең!

Башка чакта мин нәкъ шулай итәргә дә бик риза, бу юлы...

— Әби, мин бу мең тишекле ботинкамның шнурын сүтеп, аягымнан салгалаганчы, песи баласын башка берәү алып китәчәк бит!— Тавышым елаган кебегрәк чыкты.— Әйт инде, әби, алып кайтыйм инде, әби! Башкалар бүре кадәр эт тә асрыйлар әле, мин бит песи генә дим.

Әби ишек төбендәге урындыкка килеп утырды, миңа карап-нитеп тормыйча гына:

— Адәм баласы яшәгән җирдә мәче булырга тиеш инде ул,— диде. Аннары миңа сөйли башлады.— Авылда торган

---

[1] Гозереңне — үтенечеңне.

чакта безнең дә мәче бар иде. Куян атлы. Ап-ак иде. Исемен дә төсенә карап куштык.

— Минеке кап-кара, әби! Менә синең шушы йон җебең кебек. Үзе кап-кара, күзләре генә ямь-яшел, ут кебек яналар.

Әби кисәктән кырыс кына сорап куйды:

— Чем-карамыни, балам?

— Сумала кебек, әби, андый кап-кара песи берәүдә дә юк.

— Андыйны асрарга ярамый шул, шуңа күрә юк та ул. Кирәге дә юк андыйның. Халыкта, ак табы булмаган кара мәче җен-пәриләр нәселеннән, дигән сүз йөри. Юлыңны аркылы кисеп үтсә, бәхетсезлек чыгаручысы шул инде аларның. Җеннәргә катнашы юк икән, аның муенында бармак бите кадәр ак бизәге ялтырап тора.

Андый бизәк аркасында гына эшне зурга җибәрәсе килмәде:

— Аның кадәр генә бардыр инде, әби,— дидем.— Бар, бар, искә төште, мин аны башта гына күрмәгәнмен, ияге каплаган иде.

Әбием елмаеп җибәрде.

— Ярар,— диде.— Тагын бер тапкыр тикшер дә, ак табы булса, алып кайтырсың, җүнле кешенең йортында мәче асралырга тиеш. Кала җире дип, ата-баба гадәтләрен онытырга ярамас.

Очтым гына. Классташым янына атылып барып кердем дә:

— Бир песи балаңны!— дидем.— Әби рөхсәт итте.— Шунда, «кылт» итеп, әбиемнең кисәтүе искә төште.— Карале, Гөлнур, аның муенында ак бизәге бармы?

Гөлнур көләргә тотынды:

— Ак төк бөртеге генә булса да, бу песи әллә кайчан очкан иде инде,— ди.— Агы юк шул. Күрше малайлары, алып киткәч, кире кайтардылар. Барысының да әниләре борып чыгара.

Бик күңелсез булып калды. Мин йомшак диванда нәкъ

йомгак кебек бөгәрләнеп яткан песи баласына карадым. Янында әнисе утыра. Сакчы диярсең! Ул, берәүдә дә очрамый торган чем-кара баласы булганга, бераз масая да кебек. Минем ник килгәнемне дә сизенә бугай. Күзләремә туп-туры текәлгән. «Мин баламны юри кап-карага буядым, берәүгә дә бирмәс өчен»,— дигән сыман, күзен кысып, хәйләләп карый.

— Гөлнур, песи йонын буяп була микән?

Гөлнурның күзе маңгаена менде.

— Белмим, әйдә буяп карыйк соң!

Ярты сәгатьләп вакыт үткәндерме-юктырмы, мин инде әби янында идем. Курткамны иплэп кенә чиштем дә куенымнан җылы кара «йомгак»ны чыгарып, ишек төбенә җәелгән паласка утырттым.

— Менә, әби, нәкъ син теләгән җирендә ап-ак бизәк ялтырап тора!— дидем.— Мин аны күрмәгәнмен, ияге каплап торган.

Песи баласы башын селкеп җибәрде. Аякларын рәтләп басты, үз-үзен тәртипкә китерергә тотынды. Арт аягының тырнак очы белән ияк астын кымтырыклый бу. Чәнти бармак бите кадәр генә алсу телен күрсәтеп, ялап-ялап та алгалый. Гөлнур белән мин сылаган акшарлы буяу паласка коела, песиемнең ак бизәге кимегәннән-кими бара. Әби эндәшми, карап кына тора. Үзе елмая да әле. Эчемә жылы йөгерде. Минем әбинең күзләре начар күрә, газета укыганда, ул күзлек тә кия, кулына саплы лупа да ала. Идәндәге песинең табы бетә барганны каян күрсен инде ул!

— Булдымы, әби?— дидем мин кинәттән батыраеп.— Инде мин песине үз бүлмәмә алып керим. Әйдә, сөт тә эчерермен,— дип, песи белән дә сөйләшкәндәй итәм.

Әбинең тавышы усалланып яңгырады:

— Тимә! Чистарынып бетсен!— диде.— Ул бит әле җүнләп юына да белми. Кызганмыйча шуны акшарга батыргансыз!

Сизгән икән әби, күргән икән. Мин иелгән урынымда кый-

мылдарга да куркып торам. Телемә килгән беренче сүзне генә әйтә алдым:

— Әби, әби, ни, мин...— Яшемә буылып тукталдым.

Көтмәгәндә, уйламаганда әбием, бөтен тирә-якны яктыртып, ишек төбендәге тар аралыкны киңәйтеп, кеткелдәргә тотынды.

— И бала, бала! Елама, бу кадәр дә яраткач, калдырырсың инде, асрарбыз. Төсе кара булганга, җан иясенең гаебе юк, күңеле сафлык белән тулы икән бит. Күр, синең гаебеңне ничек тырышып юа, сине дә агартмакчы була, алдашмаска өйрәтә.

Шул көннән кара песи баласы бездә яшәп калды. Без аңа, Габдулла Тукай китабыннан алып, элекке көрәшче Карахмәт исемен куштык.

Песи биләмәләре

Карахмәт безгә тиз ияләште. Килеп кергән сәгатендә үк бөтен бүлмәләребезне тикшереп чыкты. Аның әйберләр белән танышуы сәер икән: күрә, исни, тирәли әйләнә дә ышкынырга тотына. Әби аңлата:

— Ул шул урында безнең күзгә күренми торган төген, исен-кушын калдыра. Янәсе: «Бу тирәдә итәк-чабуларыгызны җыеп кына йөрегез, болар — минем биләмәләрем!» Ятлар кермәскә, чик тамгалары сугып чыга.

— Безнең ул тамгалар белән санашмауны белми микән?

— Аның чикләре безнең өчен түгел ул, кызым,— ди әби.— Безне ул бар дип тә белми. Аның уенча, өйгә ул гына хуҗа. Тамгалары үзенең мәче халкы өчен аның. Менә син өйгә бүтән бер мәчене кертеп кара — күрерсең!

Миңа җитә калды. Ишегалдында яшәүче Марфуша исемле йончып беткән карт мәчене Карахмәт белән очраштырырга карар кылдым. Моның өчен өйдә үзем генә чакны көтәргә

кирәк иде. Әти-әни һәрчак эштә, менә әбине генә беркая да җибәрер хәл юк. Сөт кибете белән аптекага ул мин мәктәптә вакытта барып килә.

Аулак көн туры китерә алмый яз житте. Беркөнне әбием, мин кайтканда, матур күлмәген киеп, ак челтәр шәлен бөркәнеп, кунакка китәргә җыенып тора иде.

— Ахирәтем Фатыйма чәйгә чакыра, бер-ике сәгатьсез кайта алмам,— диде.

Әбине озатуым булды, урамга йөгердем. Марфуша ишек төбендә үк, җылы су торбасы үтә торган коеның түм-түгәрәк капкачы өстендә йокымсырап утыра. Күтәреп алдым да өйгә элдерттем. Марфуша йон йомарламы кебек җип-җиңел, дердер килә. Ач икән ул бичара, туңып та беткән. «Туйганчы бер ашатырмын да»,— дип уйлыйм.

Без ишектән керүгә каршыбызга Карахмәт йөгереп килеп житте. Кулымдагы Марфушаны күргәч, ул елмаеп җибәрде. Чын, чын! Безнең Карахмәт елмая да, елый да, көлә дә белә. Кайберәүләр: «Кит моннан, мәче ничек елмайсын инде, сөйләмә булмаганны!» — диләр. Гөлнур гына ышана. Песинең елыймы-көләме икәне күзләреннән беленә. Шат песинең күзләре сөенечтән балкып яна. Әнә Марфуша килеп кергәч, Карахмәтнең гаҗәпләнү катыш шатланып караган күзләрен күрсәгез, песиләр елмаюына ышанмый калмас идегез. Тик Марфуша аңа бик ачылып китмәде: «У-у!— дип, авыз эченнән зарланып алды.— Уу-уу!» Бу аның: «Ашыйсым килә әле, синең белән сөйләшеп торырга хәлем юк»,— диюе булды бугай. Карахмәт бездә яши башлаганнан бирле мин песиләр теленә төшенәм кебек. Марфушаның кухняны ничек тиз табуын да аңлыйм. Мәче халкы азык-төлек исен әллә каян тотып ала ул. Карахмәт белән без кухняга килеп кергәндә, Марфуша песи савытындагы калдык-постыкларны ашыга-ашыга ашый иде. Моңа Карахмәтнең ачуы чыкты. Читкәрәк китеп карап торды. Ачуланырга тотынды: «Бу нинди тәрбиясезлек! Мәче-

ләр данын сатып, эт кебек хаптор-хоптыр ашарга ярыймы? Ничек оят түгел, аа-аау! Мия-а-у! Каян өйрәндең бу этлеккә?!»

Тегесенең тукталырга исәбендә дә юк: «Эләккәндә ашап калыйм, аа-ау, ыы-ыам»,— ди дә сыпырта гына. Карахмәт аның аркасына төртеп тә карады. Марфуша: «Аа-ай!— дип, зур тавыш күтәрде.— Ууу! Фышшш!» — диде. «Комачаулама!— янәсе.— Җылы өйдә синең кебек симереп ятарга җиңел ул, андый чакта тәрбияле булырга рәхәт. Менә син минем кебек атнасына бер ашап торып кара, тәрбиялелекнең ни икәнен белерсең!»

Карахмәт аның аркасына тагын сукты. Бу юлы, тырнакларын чыгара төшеп, ныгытып сукты. Аннары кунакның сырт өстеннән умырып капты. Җибәрми тора. Өйне көчле җил-давыл вакытындагы сызгыру, улау тавышлары тутырды. Карахмәт борын аша гына: «Ы-ыы! И-ии!» — дип, саңгырау тавыш бирә. Тегесе чиелдык ризасызлык белән ачулана: «Мии-яау! Аааау, аауу!» Аннары ул кинәт: «Ах, ах, ах!» — диде дә, ялт борылып, сыртына ятты, Карахмәтне ал тәпиләре белән үзенә тартты, арткы аякларының тырнаклары белән ермачлый башлады.

Карахмәт шактый зур үскән иде инде. Ул таза, йоннары елкылдап тора. Марфуша һөҗүмгә күчкәч, миңа үз песием бик кызганыч тоелды, урамның бу усал мәчесе аны харап итәр кебек иде. Тик аларны араларга кыюлыгым җитми, мәче тырнагының ни икәнен яхшы беләм. Нишләргә?

— Перс, перс!— дим.

Ачулануымны ишеткәч, Марфуша, ук булып, кухнядан чыгып чапты. Артыннан Карахмәт атылды. Мин чыкканда, Марфуша зал уртасында, дүрт аягын өскә чөеп, сыртка яткан, үзе яман фышылдый иде. Безнең песи арка йоннарын күперткән, көлтәдәй койрыгын дугаландырып җибәргән, Марфуша тирәли биеп йөри. Мине күрүгә, Марфуша да аякларына басты. Йоннарын кабартканга, ул галәмәт зурайган, күзләре ут яна,

миелдавы да җир астыннан килгән кебек шомлы. Карахмәт аннан көлә шикелле: «Ә-әү, ми-ии!» — ди. Бу яшь песи егетенең болай шаяруы Марфушаның җен ачуларын кайната. Ул күз ачып йомганчы Карахмәтнең битенә ялт иттереп бер-икене сукты, борынын тырнап алды. Минем песинең моңа да исе китмәде: «Ми-яу!» — дип, көлеп кенә куйды. Янәсе, әйдә, дуслашыйк, кәҗәләнмә, барыбер беркая да китә алмыйсың, бу — минем биләмәләр. Ахыр чиктә Марфушаның сабырлыгы бетте, Карахмәтнең мыскыллы елмаюына түзәр чамасы калмады. Ул залны сикереп кенә үтте дә әтиләрнең йокы бүлмәсенә атылды. Карахмәт эзәрлекли китте. Марфуша, ары атлар урын юклыкны сизеп, тәрәзә төбенә сикереп менде. Безнеке кыска, юан тәпиләре белән нык-нык басып һаман аңа якынлаша. Шуннан калганын мин күрми дә калдым: Марфуша челтәр пәрдәне баскыч итеп, югары үрмәләде дә форточка турысында юк булды.

Ашыгып килеп тәрәзәне ачтым. Урам мәчесе һәлак булгандыр инде, дип бик кайгырдым. Без бит өченче катта яшибез. Шуннан сикереп кара әле син. Ачык тәрәзә төбенә Карахмәт тә менеп утырды. Мин аны-моны абайлаганчы, ул Марфуша белән сөйләшә дә башлады. «Ии-ий!» — дигән иде, астан, өрәңге төбеннән аңа Марфуша җавап кайтарды: «Мий-яау!» Карахмәт тозагыннан үзенең иркен биләмәләренә чыгып котылган урам мәчесе хәзер бездән көлә шикелле: «Менә монда аяк басып кара син! Күрсәтермен күрмәгәннәреңне!» — ди сыман.

Мин Карахмәтнең тоныкланып калган карашында, авыз эченнән генә: «Ии-ий»,— дип сукрануында аның бик нык кимсенүен сиздем. Башыннан сыйпап тынычландырырга теләдем: «Ярый, менә тагын бераз көт тә, мин сине бакчага алып китәм, анда синең биләмәләрең дә иксез-чиксез булыр, сабыр ит!» — дидем. Ул нидер аңлады бугай. Ал тәпиенең йомшак табаны белән тырналган борынын капшап карады да үз урындыгына менеп утырды, йокымсырый башлады.

Күршеләргә, кунакка

Җәйге каникул айларында мин әби белән бакчада торам. Бу юлы мин Карахмәтне дә үзем белән алып бардым. Кулымнан төшереп, бакча өенең болдыр баскычына утырткан идем, ул, инде безгә таныш гадәтенчә, тирә-юньне күзәтә, иcни, тамгалый башлады. Безнең өй, безнең бакча гына аңа аз тоелды, күршеләрнең йортларын да үзенеке итеп тамгалап кайтты: Роза апаларныкын, Хәкимҗан бабайларныкын, Володяларныкын, Кәрим абыйларныкын урап чыкты. Кәрим абый, аны күргәч, бик шатланды: «Менә рәхмәт, күсе-тычкан халкына көн калмый икән, югыйсә кармак бауларыма кадәр теткәләп бетергәннәр иде»,— диде.

Карахмәт бакчада нәкъ мәчеләрчә яши башлады. Көне буе йоклый, кичкә таба, сизми дә калабыз, чыгып китә, таң алдыннан гына кайта. Керүгә минем ятак янына килә, юрганымны тарткалый. Мин алай гына уянмасам, беләгемне тырнарга да күп сорамый. Ник уятканын беләм мин аның: торып, аңа ашарга бирүемне тели.

Бер кара төндә мин баш очымдагы тәрәзә янында шомлы тавыш ишетеп уянып киттем. Пәрдәне күтәрсәм, куркуымнан йөрәгем ярылырдай булды: кап-караңгы бушлыкта ике борчак ут яна, нидер тәрәзә пыяласын сыдыра. Пәрдәне тиз генә төшердем дә, юрганымны баштан ук томалап, тагын йокламакчы булдым. Тик йокы качкан, җитмәсә, тәрәзә пыяласын кемдер һаман сыздырып-сыздырып ала. Әби янына күчеп ятарга да куркам. Тын да ала алмый башладым. Шулчак тәрәзә ягыннан таныш, сөйкемле мияулау ишетелде. Карахмәтнең өйгә керергә соравы икән: яңгыр сибәләгәнгә, бу төндә ул иртәрәк кайтырга уйлаган.

Әби, бу хәлне ишеткәч, Кәрим абыйны алып кереп, ишек астына мәче сыешлы уем ясатты. «Авыл келәтләренә гел шулай тишек уйдыралар,— диде.— Песи халкы үзе теләгән вакытта йөрерлек булсын!» Икенче көнне Карахмәтнең бу уе-

мыннан каравылчы бабайның Йөнтәс исемле көчеге килеп кергән иде. Карахмәт, йоклап яткан урыныннан атылып төшеп, тегене тырнаклы тәпиләре белән эләктереп тә алды. Аркасы белән идәнгә сыланган, шәфкатьсез рәвештә таланган көчек үзәк өзгеч тавыш белән чинарга-еларга тотынды. Карахмәт талавыннан туктагач, ул уктай үз өйләренә чапты, капка төпләренә җиткәч кенә: «Һау!» — дип, бер аваз салды. Минем ярата торган көчегем шул очрашудан соң безгә килмәс булды. Ул Карахмәтнең усаллыгы турындагы хәбәрне башка җәнлекләргә дә таратты, ахры: ишек уемында башка һичнинди җан иясе дә күренмәде. Карахмәт үзе генә кайчан теләсә, шунда кайтып-китеп йөри торган иде.

Шулай да ул әле мине тагын бер таңда вакытсыз уятты. Юрганымны тарткалавына гына исем дә китмәс, күземне дә ачмас идем әле, Карахмәтнең усалланганда чыгара торган: «Уу-уу!» — дигән шомлы авазын ишеткәч, йокым качты. Булмә шактый якты иде инде. Минем уянганымны сизеп, читкәрәк китеп утырган песием елмая иде.

— Нәрсә булды инде тагын?— дим.

Песиемнең шатлыгы эченә сыймый, ә үзе: «Ии-ий! Уу-уу!» — дип, борын аша усаллык галәмәте чыгарып утыра. Ипләбрәк карасам, Карахмәтнең мыегыннан да озынрак булып аның авызыннан тырпайган күксел юан җеп күреп алдым. Үзе җеп кебек, үзенең җаны да бар, селкенеп-селкенеп куя. Сөенечемнән башым күккә тия дип торам. Карахмәтем гомерендә беренче тапкыр дошманын әсир итеп алып кайткан икән бит! Авызы тулы — тычкан гәүдәсе! Кыюлыгын тоеп йөрсәм дә, аңардан мондый ук батырлык көтми идем әле мин, бик бәләкәй бит әле ул, бер яшь тә тулмаган.

Бу зур вакыйгадан соң бакчадагылар арасында Карахмәтнең дәрәҗәсе кинәттән үсеп китте. Үзебез шәһәргә кайтканда, күршеләр аны кунакка алып калалар иде. Кәрим абый да үтенеп керде: «Миңа да бирегез әле, зинһар!» — дип ялынды. Бер-ике тапкыр калды ул аның белән. Шулай да бер ки-

түебездә серне чиште: «Әйтсәм, әйтим инде,— диде,— Карахмәт безнең өйдә тычкан тотмый, кармагыма эләккән балыкларны гына ашый да тиз-тиз сезнең өйгә кайтып китә».

Әби кеткелдәп көлде. Кәрим абый чыгып киткәч, миңа аңлатты:

— Карахмәт ул, кызым, сине бик ярата, шуңа күрә, син юкта да, өйдән китми, кайтырыңны көтә,— диде.

Миңа оят иде. «Песи булып песи дуслыкка хыянәт итми, мин, җүләр, аны ташлап китәм», дип уйладым. Шуннан соң аны ялгыз калдырмый торган булдым.

Үз дуслары арасында

Бездән күрмәкче, димме, икенче җәйдә бакчага песи алып килүчеләр арта башлады. Җәйге яллары җитүгә, гаиләләре белән бакчада гына яшәп ятарга тәвәккәлләүчеләр песиләрен дә үзләре янына алырга булганнар.

Безнең өйдән ерак та түгел Габдулла абыйларның җете зәңгәргә буяган биек йортлары бар. Шунда да Елгыр исемле, көлдәй күгелҗем, нәзек озын гәүдәле, гел җир ягалый сузылып йөри торган яшь кенә песи малае яши башлады. Аны Габдулла абый, озынча кәрзингә утыртып, үзе күтәреп килде. Ярата бугай. Беренче көннән үк Елгыр өчен балык каптырырга тотынды ул. Елгыры да күл балыгын ошатты, ахры. Габдулла абый:

— Кара, мондагы чәнти бармагы шае балыкка исе китте. Һич туйдырыр хәл юк,— дип гаҗәпләнеп сөйли.— Болай булгачыннан, ерактагы күлгә йөрергә туры килә инде.

Чыннан да шулай булып чыкты. Күл балыгына бик тә өйрәнеп киткән Елгыр шуннан башка бер ризыкны да ашамый башлаган. Өзлексез чинап, гел балык кына даулый. Безнең яндагы бер коштабак зурлыгы күлдә балык алай мыжлап ятмый, әби әйтмешли, күргәзмә өчен генә йөзәләр алар. Көне буе яр буенда утырсаң да, балык бик аз эләгә. Аны өзлексез

каптырырга кешедән дә яхшы түгел. Песи асрыйм дигәч тә, ул хәтле!

Абдулла абый да бу хәлгә бик вакытында төшенде. Ерактагы җәйрәп яткан зур күлгә йөрергә чамалаган. Тик бу сәфәре дә шома гына башланып китмәде аның. Беренче көнне караңгылы-яктылы торып чыкса, ни күзе белән күрсен, Елгыр да хуҗасына ияреpгә әзерләнгән. Песи генә диген син аны! Хәер, песи халкы бик тиз чамалап өлгерә ул. Кем аны ярата, кем күпсенә, кем бөтенләй янына китермәү ягын карый — бөтенесен сизеп торалар алар. Бу юлы, күк гөмбәзен тишеп үтәрдәй озын кармак сабы тотып, сәфәр җыенган Габдулла абыйның балыкка баруын Елгыр әллә каян белеп алган инде. Шуңа күрә, хуҗасыннан да иртәрәк торып, битен-күзен юып, баскыч төбенә чыгып утырган. Хуҗа агай кармагына тотынуга, Елгыр да аңа ияргән. Ул бит моңа кадәр дә Габдулла абый белән күл буена йөри иде. Тик нәни күл зәңгәр өйнең янында гына ул. Ерак күлгә шактый барасы бар. Габдулла абый башта песиенә елмаеп кына караган: «Ярар, арымасаң, миңа барыбер, әйдә, ияр!» — дигән. Бакчалар мәйданын тотып алган койма янына җитеп, каравылчы өенә сыланып торучы капкага кагылулары була — болар каршына бозау чаклы эт килеп баса. Үзе әйбәт кенә эт ул. Бакча хуҗаларын таный, әмма мәчеләрне җене сөйми аның. Песиләр дә аңардан шүрлиләр. Көндез бу зур этне бәйдә тоталар. Шуңа күрә песиләрнең күбесе аны белеп тә бетерми. Елгырның да беренче күрүе икән. Күреп тә ала, әллә кая әрәмәлекләр арасына сикерә дә.

Ул көнне Елгыр зәңгәр йортка бөтенләй кайтмады. Габдулла абый: «Бөтенләйгә югалуы инде бу моның, әрәм булды, бигрәк акыллы иде, шул котсыз эт кенә харап итте»,— дип, төне буе сукранып йөрде. Елгыр исә адашмаган икән. Әллә кайларда буталып, койрыгына былтыр көздән калган тигәнәкләрне ябыштырып, икенче көнне кайтып егылды ул өйләренә.

Әле шулай ашыгып, арып-талып кайтса да, алдына салган

ризыкларны ашамый. Азрак сөт кенә эчкән. Ит кисәкләрен дә, колбасаны да иснәп кенә карый икән дә, Габдулла абыйның күзенә текәлеп, кычкыра икән:

— Мияу! Мияу! Кайда соң синең таңнан чыгып китеп, күлдән алып кайткан балыкларың? Минем балык ашыйсы килгәнне белмисеңмени? Мияу!

Шул кәмиттән соң Габдулла абый Елгырны үзе белән бергә, әлеге озынча кәрзиненә утыртып, кәрзинне велосипедның арттагы утыргычына беркетеп йөртә башлады. Кәрзин капкачлы. Капкачында Елгырның башы сыярлык кына тишек тә бар. Бер карасаң, барысы да көйләнгән, яхшы, рәхәтләнеп, әллә кайдагы күлгә кадәр дә сәфәр чыгарга була. Алай да бер көнне Габдулла абыйның кәефе тагын бозылган әле.

Елгыр белән икәүләшеп, велосипедка утырып, ерактагы күлгә юл алулары гына була, песи ягыннан коточкыч тавыш чыга: «У-у, ау, вау!!!»

Мәче тавышына охшамаган да, әллә нинди кыргый җанвар улавы белән бер, ди. Ул дәһшәтле тавышның шул йон йомгагы кадәре песидән чыгуына ышанырлык та түгел икән.

Габдулла абый барган җиреннән шып туктый, борылып Елгырына карый. Ни күрсен, мәче кәрзиненнән чыгар өчен тартыла, тик капкачтагы кечкенә тишеккә сыеп кына бетми икән. Күзләре яшелле-зәңгәрле очкыннар чәчә, бик яман зәһәрләнеп карыйлар, ди. Велосипедын туктатып, хуҗасы:

— Ни булды, Елгыр, ник алай усалландың?— дип, йомшак кына эндәшкәч тә, мәченең тынычланырга уе юк, һаман: «У-у!» да «Ву!» — һаман улый, һаман борсалана икән. Габдулла абый аның кәрзинен тирә-яклап карап чыга. Тикшерә торгач, үзенең дә күзләре шар була. Песинең, бичараның, койрыгы кәрзин төбендәге тишектән чыккан да велосипед көпчәгендәге озын, нечкә энәләр арасына кергән. Көпчәк әйләнә башлауга койрыкның нәкъ очыннан, иң сизгер, иң авырта торган җирдән бер тотам йоны йолкынып чыккан.

Елгыр шифалы май сыланган марля белән кысып бәйләнгән койрыгын әллә ничә көн сөйрәп йөрде. Аннары терелде. Габдулла абый белән балык каптырырга гел бергә бара торган булдылар.

Дөрес, бакчада яшәргә килгән песиләрнең барысы да Елгыр кебек гаугалы түгел. Нурия апаларның Песи-Гөлҗамалы тып-тыныч гомер кичерә. Алдына ни куйсаң, шуны туйганчы ашый да, тәпиләрен сузып җибәреп, рәхәтләнеп йоклый. Әби әйтә: «И, кара инде бу карт мәчегә! Тәүлектә тагын егерме дүрт сәгать булса, анысын да йоклап тутырыр иде»,— ди. Минем әби әйтсә әйтә инде ул. Озак уйлап тормый. Нурия апа мәчесе йокласын өчен генә тәүлекнең дәвамы үзгәрәме соң инде?! Ул бит — кояш белән, Җирнең хәрәкәтләнү тизлеге белән, тагын әллә нәрсәләр белән бәйле вакыт. Их, әби, әби. Әйтер идем дә, үпкәли. Аннары ачулана ук башлый: «Мине өйрәтергә башың яшь әле»,— ди. Шуңа күрә мин аның кызулык белән ычкындырып-ычкындырып җибәргән хаталары турында аны-моны эндәшмим. Эчтән тынам, тыштан көләм— үтә ул. Нурия апаның каралы-җирәнле карт мәчесе өчен әбине үпкәләтер хәлем юк.

Аның каравы безнең Карахмәт ул Песи-Гөлҗамалга һич тынгылык бирми. Тегенең болдыр өстенә җәелеп ятуы була, Карахмәт мыштым гына янына барып та җитә.

— Мә-әү?! — ди ул.— Мәү-әү?

Песи-Гөлҗамал теләр-теләмәс кенә башын күтәрә дә:

— Ыж-ж! — дип, гайрәт чигә. Кит, кит, бимазалап йөрмә, янәсе.

Чакырып-чакырып та, уйнарга-шаярырга күндерә алмагач, Карахмәт, тырнакларын да бераз чыгара төшеп, алгы тәпие белән тегенең симез ботына берничә тапкыр төртеп-төртеп ала. Бу һичкем аңлап өлгермәслек тизлек белән башкарыла. Песи-Гөлҗамал, аны-моны төшенеп, каршы һөҗүм өчен сикереп торганда, безнең Карахмәт, әллә кайчан өйгә кереп, йомшак кәнәфигә чумган була инде.

Күршедәге песиләрнең берсе балык каптыру белән мавыккач, икенчесе «йокы чүлмәге»нә әйләнгәч, Карахмәткә башка чара калмады: таңнарның берсендә учка сыеп бетәрлек нәни песи баласы ияртеп кайтты. Кайдан тапкандыр?!

Карахмәт кебек үк кап-кара иде ул, борчак кадәре күзләре ямь-яшел, үзе өйгә керми, кеше-фәлән якынлаша башласа, курка: сыртын кәкрәйтә, йоннарын кабарта. Гадәти чагында тегәрҗеп кебек кенә нечкә койрыгы төлке койрыгына әйләнә. Шулар өстенә, яман гайрәтле тавышлар чыгара әле ул: выжылдый, фышылдый, аннары авызын зур ачып, бик каты итеп кычкыра. Чыпчык йомыркасы кадәре генә башы кыпкызыл эчле олы авыз куышлыгына гына әйләнеп калган кебек була.

Әби бу кунак песи баласын күргәч:

— И-и бичара, моны ташлап киткәннәр бугай,— диде.— Бөтенләй өзлеккән, ач бу. Кыргыйлана башлаган.

Ишек төбенә якын килергә дә курыккач, янына барганны да яратмагач, без бу бәләкәчкә ничек ярдәм итәргә дә белмичә, аптырашта калдык. Карахмәт, өйгә кереп, үзенең «табынына» борын төртте. Ул, бер тотынса, бик килештереп, ипләп кенә, озак итеп туена. Бу юлы кереп китүе булды, ялт итеп әйләнеп тә чыкты. Авызында — шактый зур гына балык кисәге. Без аңа хек дигән диңгез балыгы пешерәбез.

— Ник монда алып килдең аны, Карахмәт? — дим.— Бу нинди гадәтсезлегең тагын? — Табындагы берәр ризыкны утырган җирдә ашамыйча, кулга тотып, теләсә кайда чемченеп йөрсәм, әби мине шундый сүзләр белән тирги.— Авыз күтәреп урамда ашап йөрмәкче буласыңмы?

Минем сүзләрнең үзенә карата әйтелүен сизенсә дә, Карахмәт борылып та карамады, койрыгын гына болгады. Мин аның кая таба китүен, бу сәфәрнең сәбәбен белергә теләп, шаккатып карап торам. Карахмәт еракка китмәде, әлегәчә өзлексез кычкырып, калтыранып торучы куркак песи баласы янына барды да авызындагы балык кисәген, күчтәнәч итеп, аның алдына салды. Үзе:

— Ә-ә-әү! Мә-әү! — дип, сыйларга ук тотынды.

Кыргыйлаша башлаган песи баласына шул гына кирәк икән. Ул, сабырсызланып, әлеге сыйга ябышты.

Шул көннән башлап минем Карахмәтем телдән калды, тынычлыгын җуйды. Без табын янына утыргач, ямьсез үк тавыш белән, өстәлдәге итле ризыкларны сорый. Бирсәң, авызына эләктерә дә бакчабызның карлыган рәтендәге аргы почмагына чаба. Мин беләм инде: теге кыргый песи иң куе карлыган төбен үзенә «өй» итеп сайлаган. Хәзер ул үзе әллә ни курыкмый. «Өе» янына якынлашкан кешегә һөҗүм ясарга теләгән кебек кылана, ямьсез иттереп фышылдый, куркытмакчы була.

Мин беренче көннәрдә аны кызыксынып күзәттем. Песи сабые миңа кызганыч тоела иде. Ул Карахмәтнең сыен кабул итсә, шатланам. Тамагы туйсын, үссен, дип теләдем. Аннан соң бу нәни кунакның кыланмышлары ачуны китерә торганга әйләнде. Карахмәт үзенең бөтен ризыгын, хәтта кара төндә тычканнар-күселәр дөньясында сугышып «кулына төшергән» түшкәләрне дә аңа бирә, тегесе исә, ичмасам, азрак ягымлырак та була белми, һаман ачулы тавыш белән таләп итеп кенә утыра. Бу бер туяр, аннары көлеп-шаярып Карахмәтнең күнелен күрер, дип көттем. Юк. Тамагын туйдыра, ятып йоклый, аннары каядыр китеп, юкка чыгып тора. Кайта да тагын Карахмәтне чакырып, гауга күтәрә, ашарга сорый.

Моңарчы бик горур яшәүче Карахмәтем, бу песинең бөтен гадәтсезлекләренә риза иде. Аны тәрбияләвенә ышана иде, күрәсең. Һәм бу бурычны үзенеке саный иде ул. Миңа песиебезнең, горур башын аска иеп, болай дөнья мәшәкатенә чумуы гарьлек тоелса да, җаны теләгәч, нишләтим инде дип, чыдап торырга гына калды. Авызыннан өзеп, башканы туендыргангамы, ул ябыгып бара кебек иде. Моңарчы ялык-йолык ялтырап торучы өсте-башы да таушалып бетте, йомшак йоннары төсе уңган, шапшак, тәрбиясез эт тиресенә охшап калды. Ул бит хәзер үзенең, иске булса да, йомшак кәнәфиендә йокламый да, гел әнә шул карлыган төбен саклый. Яшь дусты кай

тарафкадыр китеп югалганда гына өйгә керә дә, теге мине тагын ташлап калдырды, ичмасам, син иркәлә, дигәндәй, миңа сыенып бераз мыраулый, азрак тынычлап йоклап ала. Уяныл китә дә тагын үз өлешен киметеп, чаба-чаба, тегеңә ризык ташый башлый.

Җәйнең эссе көннәре бигрәк тиз уза. Без су керүләрне сирәгәйттек. Әби җибәрми башлады: «Ярамый, хәзер инде суга суык энҗе төште, авыру эләктерәсез»,— ди. Шуңа күрә мин Карахмәт янында тагын да озаграк уйныйм. Гел аны күзәтәм.

Бер иртәдә Карахмәтем инде шактый бөтәеп, тазарып киткән килмешәк песи баласы яныннан бик тиз кире борылып килде. Тавышында да, хәрәкәтләрендә дә, миңа төбәлгән карашларында да аптыраш, бичаралык сизелеп тора. Авызына үзенә бирелгән ризыгын кабып, ул әле тагын берничә тапкыр карлыган янына барып-килеп йөрде. Бара да, күчтәнәчен калдырмыйча, яңадан өйгә керә. Бу ни хикмәт? Аптырап, Карахмәткә ияреп, үзем дә кыргый песи баласын карарга киттем. Көннәр-атналар буе тәмам такырланып беткән оя буш иде.

Башта мин моңа гаҗәпләнмәдем. «Ашыйсы килсә, әллә ни озакламас, кайтыр әле. Бөтенләй күренмәсә дә, әллә ни булмас, Карахмәткә бер бәла генә иде ул»,— дип уйлыйм. Уйлавын уйлыйм, тик үзем белеп торам: Карахмәт ул кыргый песине бик ярата иде. Һәм, ул яңадан кайтмаса, минем песигә бик күңелсез булачак. Мин хәтта башыма да сыйдыра алмыйм: үз тәрбиясенә алган ул песи баласын сыйпап-сыйлап йөрмәсә, нәрсә белән юаныр икән безнең Карахмәт?!

Каршылыклы шундый уйлар белән карлыган яныннан кире борылдым. Карахмәт тә, борыны аша гына моңлы зарын сузып, авызына күчтәнәчен капкан килеш минем арттан килде. Ул яшь песинең инде бервакытта да әйләнеп кайтмаячагын белгән икән. Килде, килде дә, безнең өй баскычына менеп тә тормастан, Нурия апалар бакчасына узды, алар болдырында йоклап ятучы карт Песи-Гөлҗамал каршына барып утырды. Тегесе теләр-теләмәс кенә башын күтәргән иде, Ка-

рахмәт нәни песигә дигән кучтәнәчен шул карт мәче алдына салды.

Мыр-мыр мияулады. Янәсе, мә инде, ичмасам, син кире какма! Мин бит сине дә якын күрәм, әйдә, дуслашыйк!

Песи-Гөлҗамал иренеп кенә арт санын күтәрде, чын мәчеләрчә, сабыр гына Карахмәтнең балыгын авыз итеп карады. Мин: «Әһә, болай булгач, ярый әле! Карахмәт ялгызы калмады, Песи-Гөлҗамал белән аралашып яшәргә риза булды»,— дип уйлап куйдым.

Чыпчыклар дәгъвасы

Безнең бакчадагы һәр эшне энә күзеннән үткәреп, үзенчә бәяләп йөрүче Яхъя бабай бар. Ул күп очракта әбине дә, мине дә тиргәргә, һич югында, өйрәтеп китәргә ярата.

— Чүп үләннәрен түтәл арасында калдырмагыз! — дип башлап җибәрә ул.— Аларның һәммәсендә яман чирләр булуы ихтимал. Үзләре череп бетсә дә, авырулары калучан. Кыяргапомидорга таралучан.

— Әй, Яхъя бабай, нинди авыру булсын инде аларда? — Минем бер дә артыгына йөгерәсем килми. Әле утап утыруыма рәхмәт әйтерлек.— Шунда ята-ята җиргә сеңеп бетә ул.

— Юк, алай киреләнмә. Алабутадагы чирнең чиге-чамасы юк, тик ул үзе чирләми, зәхмәт таратып утыра бирә. Әйткәнемне тыңла: тирән бер баз казы. Утапган бөтен чүпне шуна сала бар. Соңыннан тыны да чыкмаслык иттереп күмеп куй!

— Әй, рәхмәт яусын, Яхъя кордаш! — дип, әби аны хупларга тотына.— Әле дә ярый дөньясында син бар,— ди,— югыйсә бакчаларның бер яме калмас иде. Күпме киңәш бирәсең, әллә ничә китап укып та ала алмаган файдалары тиептиеп куя.

Бер караганда, Яхъя бабай гел кирегә генә тырнап йөри

кебек. Азактан барыбер бабай хак булып чыга. Шуңа күрә без барыбыз да аңардан мактау сүзе ишетергә тырышып йөрибез. Яхъя бабай исә андый сүзне бик сирәк ычкындыра.

Берсендә мин кишер түтәлен утадым. Әби күрсәтеп-өйрәтеп бирде.

— Минем билем мондый эшкә ярамый,— диде.— Үзең утап бетер инде, балам. Бер очтан сирәклəп тә бар, еш булса, юньләп үсеп китә алмый ул.

— Ярар, әби, кичкә кадәр утап та, сирәкләп тә бетерәм мин боларны...

Әйтүен дә әйттем, башкарып та чыктым. Әби белән сүз көрәштереп, аны алҗытып, үземне тиргәтеп яшәүнең кызыгын тапмыйм мин. Иртән, көн эсселәнгәнче, бер мәртәбә нygытып эшләп алдым. Төшен аллеябыздагы дус кызларым белән су буена барып килдек: коендык, кызындык. Аннары, кояш кыздыруы сүрелә төшкәч, тагын кишер түтәленә әйләнеп килдем. Чүп үләннәрен утадым, зәгыйфь кишерләрне йолкып, сирәкләндереп тә бардым. Түтәлдә карасу-яшел яфраклы нык үсентеләр генә калды. Шәп өйрәтелгән гаскәрләр кебек тип-тигез булып тезелешкәннәр.

— Менә, кызым, эшләгән эш нинди ул: түтәлең хәзер сокланып туймаслык бит, затлы келәм төсле. Югыйсә, өстенә карасаң, нәрсә чәчелгәнен дә белерлек түгел иде, алабутасы кишереннән биегрәк үсеп киткән иде.

— Хәзер мин ызанга баз казыйм да аларны шунда күмеп куям әле! — Бер макталгач, тагын рәхмәт ишетәсем килде.— Яхъя бабай шулай итәргә куша бит.

— Алабуталарын күмсәң дә күмәрсең, кызым. Тик менә сирәкләтер өчен йолкынган вак кишерләрне Яхъя бабаңнарга илтеп бир. Ул бит куяннар асрый. Әле бүген генә: «Һич азык житкерер хәл юк!» — дип зарланып торды. Илтерсең. Куян халкы, кишер дигәндә, җанын бирергә риза.

— Әй, әби, тагын ни уйлап чыгардың инде?! Кишер диярлекмени болар? Аны ничек кешегә илтим. Ачуланыр гына. Яхъя бабайга эләксәң...

Әби барыбер үзенекен итте. Миңа вак кишерләрне, яфраклары-ниләре белән җыеп, зур көлтәгә бәйләп бирде. Киттем. Яхъя бабай да мине капка төпләрендә елмаеп каршылады.

— Әй, сөенә инде куяннар! — диде.— Каян белеп китердең, кызым, ә? Бернинди азыксыз калган идек. Уралар гына, ташып өлгертер хәл юк... Һәйбәт булды бу. Куянның иң яраткан ризыгы инде бу. Рәхмәт, балам. Акыллы икәнсең: синең нужаланып үстергән яшелчәң дә исраф булудан котылды, куяннар да тук. Алар да үзләренчә сиңа рәхмәт сөйләр...

Рәхәт булып китте. Яхъя бабайдан андый сүз ишетү сирәк эләгә. Башым күккә тиде. Читлек янына килдек. Куяннар да безне сөенеп каршы алдылар. Миңа алар хәтта көләләр кебек тә тоелды.

— Матурлармы? — Яхъя бабай куяннарны бик ярата. Миңа ул хәтта бераз мактана да кебек тоелды әле.— Сабырлыгың җитеп, яхшы тәрбияләсәң, көзгә зур ук куян булып өлгерерләр алар.— Бабай миңа текәлеп карады:— Әллә соң бер парын сиңа бүләк итәргәме?

— Рәхмәт, бабай! — Минем тизрәк китәсем килә башлады. Бу сүзнең артык озакка сузылуы хәерлегә түгел.— Миңа куян кирәкми, минем песием бар, Карахмәт.

Яхъя бабайның кәефе кырылды. Сүзсез калды. Кишер көлтәсен таратып куяннарына бирде дә капка ягына кире борылды. Аның миңа нидер әйтере барын чамалап, мин дә йөгереп китми торам.

— Карахмәтне күргәләп йөрим.— Ул, әле дә шул тирәдә түгелме, дигәндәй, аллеяның ике ягына да күз ташлады. Табарсың Карахмәтне алай тиз генә! Бар! Ул кабак яфраклары арасыннан гына йөри, чит-ят кешеләрнең күзенә дә күренми.— Күбрәк аулак җирләрдә очрый ул. Су буенда, урман итәгендә. Тик...

— Ярый, бабай, китим, сау булыгыз!

— Тукта, әйтеп бетермәдем. Бакчада мәче асрауның бер

күңелсез ягы бар.— Куркынып-шикләнеп көткәнем башланды.— Мәче булган җирдә кош-корт калмый, бел шуны!

Мин Карахмәтне якларга тотындым.

— Нишләп калмасын, Яхъя бабай? — Үзем капкадан чыктым. Бабайдан тагын берәр яман сүз ишетсәм, йөгереп китеп котылмакчы булам.— Безнең сыерчыклар әллә кайчан бала очырды. Песнәкләр белән чыпчыкларны да сыйлап кына торам. Сарай түбәсенә урын ясадым, гел җим бирәм.

— Бәлки, шулаен ул шулайдыр...— Бабай йомшак кына сөйләгән арада сызып өлгерергә иде миңа.— Син, кызым, ул мәчеңне бик азындырма. Күз-колак бул, кошлар белән очрашканда ни кылануын күзәт! Мәче тик ятмас ул, ай-һай?!

— Ярар, бабай, ярар,— дидем дә очтым гына. Минем әле ерак күлдә коенып кайтасым да бар.

Шулай да Яхъя бабайның «күзәт!» дигән сүзе күңелдән һич кенә дә чыкмады. Күлгә баруның да кызыгын тапмадым. Бер-ике кат төшеп, чумып-чумып йөздем дә кайту юлына борылдым. Ник шулай вакытлы-вакытсыз әрле-бирле йөренүемә үзем дә аптырабрак тордым. «Нәрсәгә дип болай өйгә ашыктым соң әле?»

Кайтып керсәм, болдыр сукмагыннан Карахмәт килеп чыкты. Дегеттәй каралыгы, ялт-йолт итеп, әллә кайдан балкып тора, күзендәге яшел төймәгә коңгырт тегәрҗептәй нечкә аркылы сызык сызылган. Кояшлы көннәрдә аның күз карасы гел шундый сызыкка әйләнеп кала. Бармак бите кадәре генә кыпкызыл теле белән мыегын майлый. Озын койрыгын, чәнчеп, югары күтәргән.

— Ни булды, Карахмәт? — дим. Минут эчендә Яхъя бабайның шомлы сүзләре хәтергә төште.— Нәрсә ялангалыйсың?

Ул, лерт-лерт атлап, болдыр баскычыннан менде, өстәл астындагы үз тәлинкәсе ягына атлады.

— Ә-ә, сөт эчәсең килдеме? — Мин, баз капкачын ачып, чүлмәкне алдым, песиемә сөт салдым.— Мә, мә. Эч!

Үзем Яхъя бабай белән әрепләшкән кебек иттереп, уйлап куйдым: «Кечкенә кошлар тотарга, ул бит — ач мәче түгел!». Шунда ук үз-үземә нәтиҗә дә чыгардым, песигә яман сүз ишеттермәс өчен, аны гел карап, тамагын туйдырып торырга кирәк булыр.

Шулай да песинең кошларга карашын ныгыттырып бер анлыйсым килде минем. Берсендә шулай чыпчык-песнәкләргә дип, сарай түбәсендәге махсус тактага салган ипи калдыкларына ике карга очып төшкән. Шак-шок килеп, каткан кисәкләрне ашый башладылар. Аларның томшыгы зур, чыпчыклар кебек, валчыклап кына тормыйлар, зур-зур кисәкләрне шул көенчә үк йотып җибәрәләр. Менә сиңа тамаша! Кош кына диген син аларны!

Мин каргаларның ашык-пошык, ямьсез иттереп, ипи ашауларына карап дөньямны онытканмын. Күзем икенче, тагын да сәеррәк тамашаны күреп алды. Әле генә аяк арасында чуалып йөргән Карахмәт, атылып барып, сарай янындагы су кисмәге өстенә сикереп менде. Капкачы булмаса, суга ук чумар иде, мөгаен.

— Чуммый ул,— ди әби.— Әнә шул кисмәкнең бармак юанлыгы гына кырыена да басып тора ала.

Анысын беләм инде. Безнең Карахмәт яңгырлы көннәрне, аягын пычратмас өчен, койма өстеннән йөри. Ул такталар нәкъ әнә шул кисмәкнеке кебек кенә бит инде.

— Егылмаса да, анда менәргә бер тиенлек тә йомышы юк! — дидем мин. Әбинең бөтен нәрсәне белеп торуына, үземнең адым саен ялгышуыма ачуым да чыкты бугай.— Төш аннан, Карахмәт!

— Төшерерсең син аны хәзер! — Әби кеткелдәргә тотынды.— Ул әнә шул каргаларны эләктереп булмасмы дип утыра.

Бер көн эчендә песи турында ишеткәннәрем артыккарак китте түгелме?

— Әби,— дидем,— ник соң ул кошларга бәйләнә? Мин бит аны, тычкан-күселәрне куркытып, безгә яхшылык эшли дип кенә белә идем.

— Аны начарлыкка ук кертеп булмый инде, балам. Песинең гадәте шул: кечкенәрәк җан иясен үзе билгеләгән мәйданда йөртәсе килми — буа да ташлый.

— Абау! Кошларны рәнҗеткәч, ничек була инде ул? Кошсыз бакча, сыерчыксыз оя...

— Соң, уйлап кара: кошлар зәңгәр һаваларны гизеп очалар бит алар! Безнең Карахмәт бу май баскан гәүдәсе белән бер аршынга да күтәрелә алмый, ымсынуын да күпсенмик, балам! Дөнья шулай көйләнгән инде ул.

— Э-э, сиңа! Карап кына калырдайга охшамаган әле, әнә ничек сикереп менде. Күзләре дә ут яна. Ияген дә селкетеп тора... Төш аннан, кил монда, Карахмәт!

Ул арада чыпчыкларның азыгын ашап бетергән каргалар да: «Карр!» — дип берне кычкырдылар да теләр-теләмәс кенә һавага күтәрелделәр. Песиебез күзләрен очкынландырып калды. Бу юлы песине битәрләрлек әллә ни күрмәдем әле мин. Бердән, карга үзе песинең якынаюына бернинди ризасызлык белдермәде, курыкмады, исе дә китмәде. Ашыйсын ашап, сарай түбәсендә теләгән кадәр торып, үз теләге белән генә кузгалды. Шуңа күрә мин Карахмәтнең куркыныч тудыруына әллә ни ышанып та җитмәдем.

Әмма ләкин берничә көн узгач, Карахмәт белән дуслыгыбыз тәмам өзелә язды. Башта, һич уйламаганда, мин гөл кебек иттереп утап, бер бөртек чүп үләнен калдырмыйча, чисталап, йомшартып куйган кишер, суган, чөгендер түтәлләре янында кошлар чыр-чуы купты. Сәерсенеп күзәтергә тотындым. Әллә кайдан җыелып өлгергәннәр — бөтен тирә-юньне чыпчык баскан. Алмагач ботакларында да, сарай түбәсендә дә, хәтта сукмакларда да төркем-төркем чыпчык чыркылдаша.

Верандадан карап кына берни аңлашылмагач, болдырга чыктым. Куркытып җибәрмәгәем дип, акрын гына атлагандай итәм. Тик минем борчылуым урынсыз икән. Кошлар миңа бөтенләй игътибар итмиләр, үз мәшәкатьләре баштан ашкан. Анысының нидән икәнен генә белә алмыйм. Тик бик зур бәлагә төшкәнлекләре генә әллә каян аңлашыла. Чыркылдаулары, бер тыңлаганда, еламсыраган кебек, ипләбрәк карасаң, кычкыра-кычкыра нидер даулыйлар да шикелле. Шулай «ду» күчерә торгач, чыпчыклар төркеме әлеге түтәлләр өстендә оча-куна өзлексез шаулашырга тотынды. Тынычландыра да, бик теләсәң дә, куып тарата торган да түгел. Аларның бер күккә ашып, бер түтәлләргә төшеп очуы куркыныч һөҗүмгә охшаш. Нәрсәгә, кемгә мондый һөҗүм оештырганнар соң алар?

Җентекләбрәк күзәтәм, чыпчыкларның җәнҗал күтәрүләренең сәбәбен белмәкче булам. Очып кунган, тавышланып һөҗүм иткән урыннарын карыйм. Күзләрем шар булды. Түтәлләр башында, куерып үсеп утырган валериан төбендә, Карахмәт ята. Әбием дару өчен үстерә торган бу үләнне песи бик ярата. Без шуның өчен аны валериан дип түгел, песи үләне дип йөртәбез. Карахмәт, һәркөнне берничә мәртәбә шуның янына килеп, рәхәт чигә, бөтенләй йомшап-изрәп кала, сузылып ята. Күңеленнән: «Менә ул дөньяның рәхәте кайда! — дип әйтәдер кебек.— Җылы, якты, йомшак! Хуш ис таралган, и-их!..»

Карахмәт ара-тирә бер яктан икенче якка әйләнеп куя да, шул уңайдан рәхәтлеккә бирелеп китеп, ауный башлый. Менә шунда инде чыпчыкларның тавышына чыдар хәл юк: әй, чыркылдашалар, әй, кычкырышалар — дөньялары җимерелгән дип уйларсың.

Песием, шактый ара шулай ятканнан соң, торып утырды, тирә-якка караштыра башлады, чыпчыкларга да игътибар итте. Күзләрендә ерткычлык чаткылары кабынды, ияген калтыратып, тешләрен чык-чык китереп алды.

«Аһ сезне, әле монда минем ачуны чыгарып тавыш күтәреп торган буласызмы?! Хәзер тотып алам берегезне!» — дип яный кебек. Миңа аның бу кыланышы, тыеп өлгермәсәң, чыпчыкларга зур куркыныч тудырыр шикелле тоелды.

— Карахмәт! Нишлисең син, ә?! Кит аннан, кит! — дип кычкырып ук җибәрдем. «Кит!» дигәнне дә, «Кил!» дигәнне бик яхшы аңлый ул.— Кил монда, әйдә, өйгә керик!

Песи сугышчан хәленнән бераз суына төште. Атылып чыгарга җитешеп, чыпчыкларга төбәлгән күзләрен йомып-йомып куйды. Миңа таба борылды.

— Ми-и-яу! — Бу аның: «Әй, син, ник безнең эшкә катнаштың инде, бөтен планнарымны җимердең бит!» — дип, миңа үпкәләве иде.

Песием теләр-теләмәс кенә минем янга килде. Мин: «Әйдә, әйдә! Сөт бирәм мин сиңа»,— дип сөйләнгәләп аны өйгә алып кердем.

Чыпчыклар тынычландылар. Күбесе кай яккадыр очып күздән үк югалды. Кайберләре сарай түбәсендәге мин салган ярма бөртекләрен чүпләргә тотынды. Бу хәлләрнең барын да күреп торган әби:

— Чыпчыкларның бала очырыр чагы. Шуңа куркышканнар. Беләләр: зәгыйфьрәк балалары очынып-нитеп куйса, Карахмәт икеләнеп-нитеп тормый ул, каба да йота.

— Ник алай соң ул, әби? Кош баласы аулап ятмаса да ач түгел бит безнең песи. Ник алай ерткычлана ул?

— Үзе дә белештерми инде ул, кызым. Нәселе шундый аның, кәсебе шул. Көчен сыныйсы килә, нәфесен тыя алмый.

— Алай икән,— дидем дә үземә нәтиҗә ясап куйдым.

Яхъя бабай сүзләренең дөреслеге раслланды болай булгач. Карахмәтне күздән ычкындырмаска, кулдан килгәнчә тәрбияләргә, өйрәтергә кирәк. Бик тырышсам, бәлки, нәни кошларны аулап уйнавыннан биздереп тә булыр әле.



БАНУ ӘБИ САБАГЫ

Дәрес башланып киткән иде инде. Класс ишеге ачылды да «туп» итеп Әнәс килеп керде. Укытучы апа да, без дә — бөтенебез аңа борылып карадык.

— Апа, керергә рөхсәт итегез әле! Соңга калынды...

Башка берәү булса, аны күрү белән үк, укытучы ачуланырга тотыныр иде. Әнәскә алай итмәде. Ник дигәндә, Әнәснең алтынчы класска җитеп, бер мәртәбә дә дәресләргә соңга калып йөргәне юк. Ул искиткеч тыныч, тәртип бозгандагыча куркуы-фәләне сизелми. Бераз елмаебрак та тора әле.

Безнең күңелләрдә туган сорауны укытучыбыз кычкырып әйтте:

— Ни булды, Әнәс? Кил әле яныма! Инде син дә болай тиктомалдан соңгарып йөри башлагач, мин сезнең белән ничек эшли алырмын соң?

Әнәс дәү кешеләр үзара сөйләшкәндәге шикелле иттереп куллары белән ишарәләр ясый-ясый аңлатып бирде.

— Юк, апа, тиктомалдан түгел,— диде.— Мин нәкъ көндәгечә, әйбәтләп җыенып чыгып киткән идем. Күрше Бану әбинең капкасы турысына җитсәм, каршыма Гайния апа килә. «Исәнме, апа!»—дидем. «Мин исән,—ди.—Бану әбинең генә эшләре харап,— ди.— Миңа фермага бармыйча ярамый,—

ди.— Кер әле, энем, беразга,— ди,— күз-колак бул,— ди.— Япа-ялгыз хәлендә алай-болай булып куйса, ояты бөтен авылга төшә бит»,— ди. Менә шул, апа. Мин бер сүз дә әйтмәдем, Гайния апа, фермага барып, үз урынына башка бер кеше калдырып кайтканчы, Бану әби янында утырдым. Безнең очта бүтән кеше юк иде, апа. Авыру карчыкны...

— Ярар, ярар.— Укытучы апа калганын тыңлап та тормады.— Урыныңа утыр. Дәресне дәвам иттерәбез.

Башта шулай тыныч кына тыңлап утырса да, класс җитәкчебез Әнәс сүзләренең икенче ягын да уйлаган икән. Без монысын азактан гына белдек. Соңгы дәреснең кыңгыравы чыңларга гына тотынган иде, класс җитәкчебез керде:

— Балалар, бер-ике генә минутка сабыр итегез әле,— ди.— Киңәшәсе бар.

Урамга чыгып чабарга кыҗрап торсак та, укытучы, киңәшәсем килә, дигәч, барыбыз да тынып калдык. Апаның безгә киңәш итәрлек нинди йомышы булыр? дигәндәй, бер-беребезгә караштыргалап алдык. Болай киңәшләшүләр еш булмый, укытучылар күбрәк, кушалар гына бит алар. Берсендә куша, икенчесендә кушканны эшләдеңме дип, әйләндереп сорый.

Безнең гаҗәпләнү катыш кызыксынып аның ни әйтәчәген көтеп торуыбызны сизгәнгәме, класс җитәкчесе сүзен озакка сузмады.

— Иртә белән Әнәс Гайсинның сүзләрен ишеттегез бит, балалар? Әллә инде тыңлап та тормадыгызмы?

Эндәшүче булмады. Әнәс бит анда күп сөйләде, укытучы әллә кайсын сорый?! Тиз генә төшенеп җитмәдек. Без аны-моны әйтмәгәч, апа:

— Бану әби авырып ята икән бит, балалар,— диде.— Онытып та җибәрдегезмени?

— Ә-ә-ә! — дип, бөтенебез берьюлы сузып куйдык.

— Авылның ялгыз калган өлкәннәренә ярдәм итәргә кирәк дип, ничә мәртәбә сөйләштек.

— Андыйлар юк иде бит, апа!

— Әйе шул, әлегә кадәр безнең авылда сезнең ярдәмгә мохтаҗ кеше юк иде. Әнәс әнә, үзе дә сизмичә, бүген шул бик кирәкле эшне башлап җибәргән. Тик...— Укытучы елмаеп куйды.— Тик дәрескә соңга кала язды, анысы яхшы түгел. Бергәләшеп алынсак, андый хәл булмас.

Без барыбыз да шатланып ризалаштык. Инде әллә кайчан чын тимурчылар кебек өлкәннәргә булышырга атлыгып тора идек без. Бану әбинең авырып китүе — безгә күктән төшкән табыш ул.

— Нәрсәләр эшләргә соң, апа, кайчан тотынырга?—дибез.

— Анысын, балалар, мин үзем дә белмим. Бәлки, Әнәс бераз чамалагандыр.— Класс җитәкчебез Әнәскә карап сөйли башлады: — Нәрсә кирәк аңа, Әнәс? Үзе берәр ярдәм сорадымы ул синнән? — Әнәс сикереп торып басты. Бөтен классның, хәтта укытучыбызның да төп эше аңа килеп терәлгәнгә бераз һаваланып та киткән сыман. Шулай да әллә ни ачу китергеч иттереп кыланмый. Әнәс — беркатлы, ачык күңелле малай ул. Бу юлы да Бану әби турында сөйли башлаганчы ук, йөзен балкытып, елмаеп җибәрде.

— Тик кенә торганда сорамый да ул, апа. Мин үзем әйттем: «Бану әби, нәрсә ашыйсың килә, хәзер кертәм»,— дидем. Ул миңа көлгән сымаграк карады. «Сырхау кешегә ни кирәген белмисеземе?» — ди. «Шоколадный конфет!» — дим. Әбием башын кире якка борды. Конфет кирәкми. Мин тагын нинди тәмле әйбер әйтим икән? дип уйга калдым. Ул арада әби: «Чәй эчәр идем, бәбкәм,— дип ыңгырашты.— Үзем торып йөри алмыйм, башым әйләнә»,— ди.

Әнәснең газ плитәсе өстенә чәйнек куеп су кайната гына алганына без ышанабыз инде. Нәкъ шулай иткәндер, дип уйлап, аны әллә ни тыңламый да башладык. Безнең авылда бөтен өйләргә суы да, газы да кергән, чаңгылдатып агызасың да, гөжелдәп торган ут өстенә утыртасың. Минут эчендә кайный да чыга. Әнәс кенә бу хәлне алай җиңел иттереп сөйләми

тора, ник озакка сузадыр. Укытучы апага да кабатлап сорарга туры килде.

— Чәй генә кайната беләбез инде без, шулаймы, Әнәс? — диде ул.

Без инде барыбыз да Әнәснең шартлатып җавап бирәчәген белеп тора идек. Шуңа күрә аны тыңламыйбыз да, әбигә кем нинди яхшылык эшли алачагы турында үзара гәпләшәбез. Тик, ни гаҗәп, Әнәсебез эндәшмичәрәк торды. Ык-мык итте. Аннары, үз хәле үзенә дә сәер тоелды, күрәсең, көлеп үк җибәрде.

— Әйтсәм әйтим инде, апа, булмады,— диде.— Чәй кайнатып эчерә алмадым мин.

— Ә-ә-ә?! — Бөтен класс берьюлы сорады. Укытучы апа да аптырап калды. Әнәс аңлатырга тотынды.

— И, апа, ул Бану әби карап торырга гына юаш күренә икән. Аның кирелеген белсәгез! — Әнәс, әбиләргә карата андый сүз әйтергә ярамаганлыгын аңлап алып, алдан ычкындырган хатасын шомартырга ашыкты.— Болай булды, апа. Мин чәйнекне кайнатып, әбинең караваты каршысындагы сандык өстенә китереп куйдым. Чынаягына да ясап бирдем. «Эч, әби!» — дидем.

— Соң?

— Ул чәйнеккә кырын карап кына алды да стенага ук борылып ятты. Эндәшмәс булды. Мин нишләргә дә белми тордым. Бераздан: «Әби, ник эчмисең?» — дигән идем. Ул үзалдына сөйләнгән кебек кенә: «Мин суык су эчмим,— диде.— Чәйнектә кайнаган су — чәй түгел,— ди.— Минем уенчык кебек матур, җиз самавырым бар, ике елга җитәрлек күмер запасым тора, самавыр куй син миңа»,— ди. Мин шул, апа, самавыр куя белмим. Кабыза алмадым. Гайния апа фермадан әйләнеп кайтканчы, әби чәй эчмәде...

Без тынып калдык. Укытучы апа да җитдиләнде.

— Алай икән. Менә хәзер аңлашылды,— диде.— Яхшы. Алдан белеп тору хәерлерәк.

Без, Бану әби янына кемнең кайчан барырга тиешлеген ачыклап, исемлек төзедек. Һәр көнне икешәр яки өчәр кеше барырга дип килештек. Күршесендә үк яшәгәнгә, Әнәсне бу эштә иң җаваплы кеше иттереп билгеләдек.

Шуннан алып безнең класстагы һәр көн Бану әби турындагы хәлләрне сөйләшүдән башланып китә торган булды. Атна-ун көн дигәндә, классыбыздагы һәркайсыбызның нәрсәгә оста, нәрсә кулыннан килмәве барыбыз өчен дә ап-ачык иде инде.

Беренче көнне, аның өенә безнең барып йөриячәгебезне әйтергә, шуңа хуҗаның рөхсәтен дә алырга дигәндәй, Бану әби янына класс җитәкчебез дә барды. Әнәснең безгә аңлатуына караганда, әби белән укытучы икәү генә калып шактый озак сөйләшкәннәр. Аннары класс җитәкчесе киткән. Әнәскә ияреп барган ике кыз әбидән:

— Әби, нәрсәләр эшлик? — дип сораганнар.— Самавыр куйыйкмы? — Алар самавыр кабызырга махсус өйрәнгәннәр иде инде.

— Бүген хәл белә килүчеләр күп булды, идәнемне, тәрәзә рамнарын, өстәл-шкаф өсләрен тузан баскандыр. Дымлы чүпрәк белән тузаннарны сөртеп, идәнемне юып чыгарсагыз...

— Хәзер, хәзер, әбекәй! — дип, кызлар кызу-кызу эшли башлаганнар.

Тузаннарны сөртеп йөргәндә әби аны-моны эндәшми яткан. Кызлар сөйли: «Үзе йоклаган кебек мыш-мыш сулый, үзенең күзләре шар ачык, безнең эшне энә күзеннән үткәреп тора». Гөлия чапырдатып идән юа башлагач, әби ыңгырашырга тотынган.

— Нәрсә булды, әби? Кай төшең авырта? — Кызлар, куркышып, аның баш очына ук килеп басканнар.— Әллә врач чакырыйкмы?

— Юк, духтыр кирәкми. Идәнемнең йөзен күгәртәсез, шуңа борчылам,— ди икән теге.— Чупырдатып су түгүдән генә юкә идән агармас. Сез аны сабынлы су белән азрак чылаты-

гыз да, кыргыч белән кырыгыз, икенчегез чиста су белән яңадан юсын!

Әллә өч, әллә дүрт кат юдырткан идәнен. Кызлар тирләп-пешеп беткәннәр. Гөлия, үпкәләп, кайтып киткән. Әби кеткелдәп көлә икән:

— Әйдә, әйдә, үпкәләсен, соңыннан барыбер мин кушканча эшли ул. Эшләгәнегез миңа булса, өйрәнгәнегез үзегезгә калыр. Башкалар сезне, идән дә юа белми, дип, мәсхәрәләмәс, гомер буе миңа рәхмәт укырсыз...

Үзебезнең кызлар юган идән булгач, без Бану әби янына аяк киемнәребезне болдыр төбендә үк салып керә башладык. Салабыз да, итекләрне тотып өйгә узабыз. Анда идәнгә киндер җәелгән аерым почмак бар, киез итекләрне шунда тезеп куябыз.

— Һай, рәхмәт төшкерләре! — дип каршылый безне әби.— Беренче көннәрне идәнемә сукмак салып бетерә идегез. Хәзер инсафлана барасыз, моннан соң кемгә керсәгез дә, аяк киемегезне сала торган булыгыз. Сокланып туя алмаслар. «Кеше хезмәтен болай олыларга кем өйрәтте?» — дип сорасалар, әйтеп тормагыз. «Үзем беләм!» диегез...

Беркөнне Бану әби безне бигрәк тә көтеп алды.

— Һай, рәхмәт төшкерләре! — диде ул.— Әллә минем сагынуымны белдегезме, ничек болай иртә килдегез?

— Бүген биш сәгать кенә укыдык, әби, көне шундый.

— Бигрәк тә уңайлы булган икән. Мөгаллимнәрегез шәфкатьле икән.— Укытучыларны борынгыча «мөгаллим» дип йөртә ул.— Минем токмач ашыйсым килгәнне сизенгәннәрдер, шуңа иртәрәк җибәргәннәрдер.

— И-и, әби, расписаниесе шундый аның,— диештек без. Әби янына алдан килүнең әллә ни зур эш түгеллеген аңлатырга тырыштык.— Әйдә, әби, әйт бөтен теләкләреңне!

— Әйттем түгелме соң инде, оланнар! Токмач ашыйсым килә. Кинәттән генә ымсынып куйдым да нәфесемне һич тыя алмый башладым. Югыйсә сезне ул кадәр зур эш белән мәшәкатьләргә йөрәгем җитмәс иде.

— Әй, әби, нәрсәсе мәшәкать булсын аның, хәзер өлгертәбез аны! — Миләүшә дөбер-дөбер килеп аш-су ягына атлаган иде дә, әби аны шып туктатты.

— Сабыр ит, бәбкәм. Чәчеңне-башыңны җыештырмыйча ул якка үтәсе булма. Әнә мич буендагы бауга элгән ак батист яулыкны алып башыңа бәйлә, бер бөртек чәчең дә күренеп тормасын. Кулыңны җылы су белән сабынлап юып җибәр!

Әби, тагын нәрсәне онытам икән, дигән сыманрак уйланып торды.

— Аннары шуны әйтим: бер эшне дә ашык-пошык, эштерөштер сыпырып ташларга ашыкмагыз! Мин ашның да озаклап пешкәнен яратам: шулпасы лепер-лепер иркенләп кайнасын, токмачы белбелдәп торсын, шулпа өстендә җелектән сыгылып чыккан алтынсу өреләр җемелдәшсен.— Әби бераз бөрешә төшкән иреннәрен чупылдатып куйды.— Хуш исе зиһеннәрне чуалтырлык булсын.

Миләүшә:

— Ярар, алайса,— диде. Аның тавышы басынкыланып калды. Хәрәкәтләре дә сабырлана төште.— Тырышып карармын, әби. Син өйрәтеп торсаң, кушканыңны эшләрмен.

Аның савыт-сабалар шалтыратуы, су агызганы, газ плитәсенә ут үрләткәне ишетелде.

— Ит — чоландагы өсәктә [1], ваклап куйган.— Әби иләп кенә өйрәтеп тора.— Билдәмә турысын сайлап алыгыз. Токмачлы ашка сарык билдәмәсенең шулпасы килешә.

Әбинең теләгән кисәген таба алмагач, безгә чоландагы ит кисәкләренең һәммәсен әбигә кертеп күрсәтергә туры килде. Үзе һич авырсынмады, ачуланмады. Ниндирәк иттән нинди тәмле ризык пешерергә яравын аңлата-аңлата сайлана бирде:

— Һу-у, тәмле кимерчәкле кисәк! — дип сокланып карады

---

[1] Амбарда, чоланда ашлык, ашамлык салыр өчен такта белән аерым бүлеп куйган бүлем.

берсенә.— Шулпалы бәлешкә калсын монысы. Ял көнегездә килеп, һәйбәт иттереп пешерерсез. Бөтенегез килегез. Бура чаклы бәлеш салырсыз да бөтенебез бергә сыйланырбыз.

— Бездән бәлеш салу булмас инде, әби,— диештек.

— Иренмәгез генә! Иренмәсәгез, үзем өйрәтермен...

Ул арада Миләүшә барысын да әрчеп, бәрәңгесен, кишерен-суганын турап куйган.

— Әби, боларны шулпага салыйммы? — дип сорады.

— Салырсың, ашыкма! Ит тетелеп пешсен әле...

Шулай иттереп әби, сиздерми генә, Миләүшәгә ашны тәмле итеп пешерү хикмәтләрен өйрәтә торды. Мин ишегалдындагы ир-ат өлешенә тия торган эшләрне караштыргаладым. Сукмаклардан карлар көрәдем, сарыкларга печән салдым. Аннары бер-ике кочак утын да ярдым. Әби кушты. «Ял көнне бәлеш салырга уйлагач, мичкә якмый булмас»,— диде. Өйләр газ белән җылытыла башлагач та, Бану әби, мин мичсез яши алмыйм, таба ашларын пешерергә, бәлеш салырга кирәк ул, дип, өй уртасындагы олы мичен сүттермәгән. Утынын да гел әзерләп кенә тора икән.

Ишегалдындагы эшләрне беткәнгә санап, өйгә кердем. Аш-су ягыннан Миләүшә килеп чыкты. Ул бик канәгать күренә иде.

— Әби, шулпа бик тәмле булган, инде токмачын гына саласы калды,— ди.— Эзләштергән идем дә таба алмадым, токмачың әллә кайда.

— Нинди токмач?

— Соң, әби, кисеп куйган, кипкән токмачың бардыр бит инде. Безнең әни бер тотынганда күп итеп кисә дә киптерә. «Теләсә кайчан шулпага салырга әзер булып тора ул»,— ди.

Әбинең йөзендәге җыерчыкларга тулган якты нурлар сүнде, өй караңгыланып киткән сыман булды.

— Юк нәрсәгә өйрәтәләр балаларын,— дип, башта үзалдына сөйләнде. Аннары, ачыла төшеп, Миләүшәгә аңлатырга тотынды: — Юк, бәбкәм, мин алай ай буе кибеп-катып беткән,

ләззәтен җуйган токмач ашарга өйрәнмәгән. Сиңа да әйтеп куям: ризык тәмен җибәреп, ялкаулыкка юл сарып, өем-өем токмач киптермәгез. Бер-ике генә күкәйгә басып, шулпаң өлгерер алдыннан гына кискән токмачтан да сихәтлерәк ризык юк. Мин бервакытта да токмачны киптермәдем, пилмәнне туңдырмадым!

Әбинең мондый сүзләрен ишеткәч, Миләүшәнең төсе качты. Мин аптырап калдым. Ни булды икән, Бану әбинең нинди ашны ничек иттереп ашавында аның ни катнашы бар, ник шулай борчыла икән бу, дим. Хәер, бик озакка бармады, сере ачылды классташымның. Кызарынып-бүртенеп, елар хәлгә житеп, әбигә әйтергә мәҗбүр булды:

— Алайса, алайса... нишлик икән соң? — диде.— Мин бит камыр баса да, токмач кисә дә белмим. Өйдә әни пешерә. Мәктәптәге «Йорт эшләре» дәресендә токмач кисүне үтмәдек әле.

Миңа да уңайсыз булып китте. Класстан икәүләшеп кил дә шул күбәләк кебек карчыкка аш та пешереп ашата алма инде! Хурлык бит. Ир-ат эше булса, мин ничек тә үзем башкарып чыгар идем дә, камыр басуны, токмач кисүне уйлап та караганым юк. Әби үзе дә безне шундый кыен хәлдә калдыруына борчылыр әле, шулпага берәр бүтән нәрсә, я ярма, я вермишель салырга кушар, дип көттем. Юк шул, теләгәненнән баш тартырга уйлап та карамады ул.

— Бар, бәбкәм, ак эчле савытка ике йомырка сыт та чеметеп кенә тоз сал. Шуны бик озак тугла!..

Әби әйтә торды, Миләүшә үти барды. Хәзер сөйләргә генә кызык. Ул көнне икебезгә дә оят иде. Алтынчы класска җитеп Миләүшәбезнең он иләгәне дә, камыр басканы да, җәймә җәйгәне дә, токмач кискәне дә булмаган икән. Бану әби һич ашыкмыйча, иплән кенә өйрәтеп ятты. Җәймәсе түм-түгәрәк үк булып чыкмаса да, токмачлары тигезле-тигезсезрәк киселсә дә, Миләүшә башлаган эшен барыбер очлады. Вакыт шактый үтте үтүен. Минем эшләрем беткән дә иде инде. Алай да кызыбызның ялгызын калдырып китмәдем. Әби дә рөхсәт бирмәде.

— Минем белән рәттән утырып ашамасагыз, риза-бәхил түгелмен,— дип, кырт кисте.

Әйтүе — бер, әби табынында аш ашау үзе бер хикмәт булды. Түр өстәлгә ап-ак ашъяулык җәйдертте. Өчебезгә дә тастымаллар куйдыртты. Аннары, акрын гына урыныннан кузгалып, үзе дә кулларын юып килде, өстәл янына утырды.

— Бул, бәбкәм, ашыңны,— диде.

Эчемнән генә сөенеп, ярый әле Миләүшә урынында мин түгел, дип утырдым. Әби аңа тәлинкәгә ашны ничек салырга, тәлинкәне башлап кемгә куярга — бөтенесен өйрәтеп торды. Анысы гына — бер хәл. Ул безгә токмачлы ашны ничек ашарга икәненә кадәр аңлатты.

— Токмачларыгыз кашыгыгызга кереп беткән булсын, асылынып-сузылып тормасын! — ди.— Югыйсә кабып җибәрәм, дигәндә генә күлмәгеңә килә дә төшә ул.— Үзе көлә әби.— Кызык итә гадәтсезләрне.

Икенче көнне, класска барып кергәч, Миләүшә белән икәүләп, бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә, әби янында күргәннәребезне сөйләргә тотындык. Шаккатырлар, аптырашырлар, кайберләре әле барыргамы-бармаскамы дип, икеләнеп тә калырлар, дип уйлаган идек. Без көткәнчә булмады. Бану әби янына безгә кадәр үк йөрүчеләр өчен бу өйрәтмәләр гаҗәп түгел иде инде. Әби үзе янына барган безнең классташларның һәммәсен нинди дә булса яңа бер һөнәргә өйрәтеп ята икән бит! Сөйләмәгәннәр генә: әллә оялганнар, әллә вакыт тимәгән. Әле өйрәнә алмыйча, хурланып, елап, өйләренә кайтып-кайтып та киткәләгәннәр.

Миләүшә белән минем сүзләрне класс җитәкчебез дә ишетте. Алдан әйтеп өлгергәннәребезне, үзе ишетми калганнарны кабатлап сөйләтте әле. Азакта:

— Яхшы, бик яхшы,— диде ул.— Бану әби безнең класс өчен гаҗәеп табыш ул. Ничек без моны алданрак белмәгәнбез. Йорт эшләренә өйрәтер өчен аннан да яхшы остазны кайдан табар идек әле!

Шул рәвешчә, безнең әбигә ярдәм итәргә алынуыбыз икенче якка әйләнде, әбиебез үзе безгә гаҗәеп кирәкле кеше булып чыкты. Хәзер без шикләнеп тә куйгалыйбыз әле: «Юри генә авырганга салышмады микән ул»,— дибез. Чөнки, ул савыкканнан соң да, аның янына йөрүдән һич туктарга теләмәвебезне сизгәч, әби:

— Күптән сезнең кебек яшь-җилкенчәкләргә сусаган идем инде,— дип әйтеп салды.— Мин пешерә белгән аш-суларны безнең авылда гына түгел, тирә-юньдә дә белмиләр. Туй-фәлән үткәрә башласалар, утызар чакрымдагы авылларга алып китәләр иде. Хәзер картайдым инде. Кешеләрнең табыны нишләр, такыраеп калмасмы, тәмле ризыкларны онытып бетермәсләрме, дип кайгыра идем... Сезне өйрәткәч, күңелем тынычланды...

Дуслашып китүебезгә «авыруым сәбәп булды», дигән сүзне телгә дә алмады ул. Бүгенгә кадәр белми йөрибез: чыннан да авырганмы ул, әллә үз һөнәрләренә безне дә өйрәтер өчен, бераз хәйләләргә чамалаганмы? Бу хакта уйлап-уйлап куябыз без, тик әллә ни баш ватмыйбыз. Хәзер барыбер инде. Авырмаса да, көн саен безнең классның ике укучысы Бану әби янына китә. Ни кушса, шуны эшлибез: идән юу, кер уу, өй җыештыру, кер үтүкләү. Арабызда аш-су пешерүнең аерым осталары ачыкланды. Кызларның кайберләре шулпалы аш өлгертергә ярата, бүтәннәре коймак-кабартма чыжлатырга атлыгып торалар, ә чәк-чәк, кош теле, бавырсак, юка, гөбәдия, татлы бәлеш кебек чәй ашларын пешерергә барысы да өйрәнде. Самавырны малайлар хәтта тизрәк тә кайната.

Без, малайлар, авылыбыздагы оста куллы берәр бабайга да шулай «ярдәм» итәргә иде, дип уйлап торабыз әле. Шәп бабайлар бар бездә. Тик берсе дә авырмый. Авырсын иде бу дип, көтеп йөрүе дә әллә ничегрәк бит. Шуңа күрә яңа уку елы башыннан ук иң оста, иң күп белүче бер бабайның үзен мәктәпкә чакырырга әле исәп.

САГЫНУ

Көннәрдән бер көнне әнисе эштән кайтып керде дә, кулындагы кәгазь кисәген югары күтәреп, Сәет каршына килеп басты.

— Сөенчегә ни бирәсең, улым? — ди.

Кәгазьнең нәрсә икәнлеген төгәл генә белмәсә дә, алай «сөенче» кычкырырлык булгач, аның яхшы хәбәр китерүен Сәет чамалап өлгерде. Елмаеп:

— Нәрсә соң ул, әни? — дип сорады.

Куш битле кәгазьнең тышкы ягына пионер малай сурәте төшерелгән, эчендә китаптагы кебек басма сүзләр дә, кулдан язылганнары да бар. Каләм белән язганын Сәет кычкырып укыды: «Шамкин Сәет Шакирович!»

— Минем исемне нигә монда язганнар соң, әни?

— Син пионер лагерена барсын өчен шулай язганнар аны. Тиздән китәсең, улым. Колхозныкына түгел, еракка, Казаннан да ары, ди.

Берөзлексез елмаеп торучы дәү әни дә сүзгә кушылды:

— Әй, үсеп тә кайтыр инде Сәетбатталыбыз! — диде. Ул гел шулай Сәетнең исемен озайтып йөртә, тизрәк зур кеше иттереп күрәсе килә, ахры.

Сәет:

— Карап карарбыз әле, дәү әни! — диде дә, путевканы кулына тоткан килеш, урамга чыгып чапты. Әнисенең: «Югалта күрмә, улым»! — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Кызык та инде бу әни: шундый кәгазьне югалтырга ярамаганны Сәет белмиме?! Хәзер Нурсинәгә бер читен генә күрсәтеп ала да пыяла шкафка куя ич ул аны.

— Нурсинә-әү!

Күршеләрнең ак пәрдәле, шау чәчәкле яран гөлләренә күмелгән тәрәзәсеннән кап-кара чәчле кызый күренде.

— Кем тия, Сәет?

— Чык әле монда! Бер әйбер күрсәтәм, Нурсинә!

Тик кызыйның путевкага бик исе китмәде.

— Шуның өчен башың күккә тидеме? — диде.— Әллә ни түгелдер әле, мин беләм инде аны.— Нурсинә үткән җәйдә әниләре белән бергә Казанга барып кайткан иде, шәһәр хәлләрен бик яхшы хәтерли.— Анда су юк, белдеңме?! Таш юлдан барасың да барасың, эчәреңә су таба алмыйсың. Сагынырсың әле безнең Ташлыкүл чишмәләрен. Андагы эсселек, андагы ерып йөри алмаслык халык! Сабан туендагы кебек, тамашасы гына юк. Үзләре җәһәннәмгә ашыгалар сыман — юл биреп өлгермәсәң, бәреләр дә егалар.

— Әйттең сүз! — Сәет лагерьны бөтенләй башкача күз алдына китерә иде.— Бу бит шәһәр җире түгел. Андагы йортлар да шәһәрнеке кебек түгел, суы да күп, ди. Белдеңме?

Нурсинә:

— Ә-ә-э,— дигән булды. Каршы әйтер сүзе бетте. Шулай да бөтенләй җавапсыз калмас өчен: — Мин бүген Түбәноч әбиләргә барам,— диде.— Кунарга! Иртәгә генә кайтам.

Менә сөйләш син аның белән! Сәетнең Казан артындагы лагерьга җыенуын үзенең Түбәноч әбисендә бер кич кунып кайтуы белән чагыштырмакчы!..

Сәетләрне район үзәгеннән һәйбәт автобуска утыртып алып киттеләр. Әнисе озатырга килгән иде. Автобус тәрәзәсе аша бик озак карашып тордылар. Машина гөрелди башлагач, Сәет белән янәшә утырган бер кыз үрсәләнеп еларга тотынды.

Кызларның шул инде аларның, әниләре ике адым китсә, авызларын ямьшәйтеп, борыннарын мышкылдатып, яшь коярга тотыналар.

Автобус кузгалды. Әле генә күз алдында басып торган әнисе артта калды.

— Әни-и-и! — Сәет ник шулай өзелеп кычкыруын үзе дә аңламады. Әллә ничек, һич көтмәгәндә, үзеннән-үзе ычкынды да куйды. Бик оялды Сәет. Җитмәсә, теге елак кыз:

— Елама, Сәет! — дигән була.— Ничек тә түзәрбез бер айга,— ди.

Әйтерсең лә Сәет еларга җыенган! Ул бит ялгышып кына кычкырды.

Башта аларны Казанга алып килделәр. Нурсинә тузга язмаганны сөйләгән икән: кешесе дә ул кадәр күп түгел, сине бәреп егарга ашыгучысы да очрамады, суы да адым саен. Су дигәч тә, Ташлыкүл чишмәсе сыман җир астыннан бөркеп тормый ул, автоматтан чама белән генә ага. Аннан эчәр өчен иң элек өч тиен акчаңны салып куярга кирәк. Кая инде ул Нурсинәгә аларны аңлап бетерү? Йөргәндер шунда, авызын күтәреп, асфальт юлдан чишмә эзләп.

Казанда Сәетләрне группаларга бүлделәр, тәрбиячеләре, вожатый апалары белән таныштырдылар. Аннары икенче төрле машиналарга утыртып, шәһәрдән алып чыгып киттеләр.

Исе китте Сәетнең. Лагерь ул шәһәр дә, авыл да түгел икән. Әллә урман, әллә урам — һич белә алмассың. Очы күккә барып терәлгән чыршы-наратлар арасында күренер-күренмәс булып кына йортлар тора. Агачлар сирәгәйгән урында уйнар өчен зур мәйдан ясаганнар. Мәйданның кыл уртасында — теге наратлардан да биегрәк бер колга башында кызыл әләм җилферди.

Сәетнең әнисенә охшаган бер апа алар группасын агачлар арасындагы өйләрнең берсенә алып керде.

— Без менә шунда яшәрбез, балалар,— диде.— Урнашыгыз!

Шул минуттан Сәеткә рәхәт көннәр башланды. Түрдәге

сыгылмалы караватанык булды. Хәер, монда аның әллә ни кирәге дә юк. Көне буе уен да көлке. Бит юарга, ашарга-эчәргә, коенырга гел дус-иш белән кумәкләшеп йөрисең. Кайбер малайлар иртә белән йокыдан уяна алмый интегәләр. Сәеткә анысы да авыр түгел. Ул монда килгәнче әтисе белән колхоз малларын көткән иде. Иртән таң беленүгә торалар иде. Хәзер Сәетнең көтүгә чыгасы юк, яткан җире дә печәнлек түгел, колакны ярырлык иттереп кычкыручы әтәч тә юк монда — барыбер, көтү китәр чак җиттеме, күзләр шар була да куя.

Беренче көнне ул, саташып, соңга калмадыммы дип, куркынып, сикереп торды, бүлмәдән атылып чыгып та китте. Ишегалдында берәү дә юк иде әле.

Авылда әллә кайчан торганнардыр инде. Нурсинә дә яшелчә бакчасына чыккандыр, кишер утый торгандыр...

Һич көтмәгәндә быргы тавышы яңгырады. Сәет аны-моны уйлап өлгергәләгәнче, тәрбияче апа:

— Торыгыз, балалар! — дип, башкаларны да уята башлады.— Сәгать җиде тулды, ишетәсезме, әнә быргы бит ул сезне чакыра?!

Ашап-эчкәннән соң тәрбияче белән вожатый группаның алдагы көннәрдәниләр эшләячәген тәртипкә салырга тотындылар. Әлеге ак бүлмәдә чисталыкны саклау да, җыр-бию осталарының концертын оештыру да, күршедәге «Чулпан» колхозына булышу да телгә алынды. Тәрбияче бер тәкъдим ясаган саен, пионерлар мең сүз белән җавап кайтарып утырдылар. Концертка катнашырга теләүчеләр аеруча күп булып чыкты. Түбәсенә тана колагы кадәр ак ефәк күбәләк таккан кыз Сәетнең ачуын китереп бетерде. Биюче кирәк дисәләр дә, ул кул күтәрә, җырчылар турында сөйләшсәләр дә, чәрелдәргә тотына, шигырь белүчеләрнең кирәге чыккач та, ул: «Мин, мин, мин!» — дип кычкыра. Булса да булыр икән кешедәге сабырсызлык! Әйтерсең ул белгәнне башкалар булдыра алмый? Барысы турында да бугазың ертылганчы кычкырып утырырга димәгән бит! Сәет, вожатый-фәлән күрмәгәндә генә,

кыз чәчендәге ефәк тасма очыннан тартып караган иде, «тана колагы» шиңде дә төште. Шул кирәк аңа!

— Шамкин, синең бер генә һөнәрең дә юкмыни соң?

Бөтенләй эндәшми утырсаң да ярамый икән шул. Тәрбияченең соравына ни дип тә җавап кайтара алмыйча, Сәет башын аска иде. Кайсыдыр шаяртып:

— Сызгыра белә ул,— дигәч, барысы да көлделәр. Тәрбияче генә көлмәде.

— Сәнгатьчә, матур итеп сызгырса, программага кертәбез,— диде.— Концертны җанландырып җибәрер.

Сәет актан-карадан берни дә дәшмәде. «Әтиемнең гармуны монда булса, күрсәтер идем мин сезгә Сәет Шамкинның нәрсәләр эшли алганын»,— дип эчтән генә уйлап куйды. Әтисенең «Вараксин гармуны» бар. Шуны сыздырып җибәрсәң, бөтен дөнья нурга чумган кебек була. Сәет әле мәктәпкә укырга кергәнче үк шул гармунда уйный белә иде. Мәктәптә аны «безнең гармунчы» дип кенә йөртәләр.

Тәрбияче соравына эндәшми калып кына котылган иде Сәет, вожатый аны кыстарга тотынды. Имеш, концертта һәркем катнашырга тиеш. Шактый вакыт сүзсез торгач, Сәет, башын күтәреп:

— «Вараксин гармуныгыз» бармы соң сезнең? — дип сорады.— Булса, «Идел бит ул, тирән бит ул» көен уйнап күрсәтермен...

Кызганыч, лагерьда бозау кадәр аккордеон белән ындыр табагы кадәр рояль генә бар шул. Их, мондый хәлне авылда чакта белсә, ничек итсә, итәр, әтисенең гармунын әләктереп килгән булыр иде. Зур түгел бит ул, култык астына да сыя.

Малайның сөмсере коелганын күргәч, вожатый апа тынычландырган булды:

— Ярый, Шамкин, борчылма! Без сине спорт ярышларына катнаштырырбыз, әзерләнеп тор! — диде.

Инде Сәет зур өметләр баглап торган спорт уеннарын телгә ала башладылар. Берсе кемнең нинди уенга осталыгын сорап тора, тәрбияче язып бара.

— Кем йөгерергә оста?

Берьюлы тугыз-ун кул күтәрелде. Фамилияләрен теркәп куйдылар.

— Кем озынлыкка сикерергә тели?

Тагын куллар күтәрелә, тагын теркиләр. Шул рәвешле биеклеккә сикерүчеләрне дә, гимнастикага өйрәнгәннәрне дә, тиз йөзүчеләрне дә, көрәшчеләрне дә — барын да яздылар. Үзенең иң яраткан уены телгә алынмасмы дип, күпме көтте Сәет — булмады.

— Син, Шамкин, тагын читтә калдыңмы?—Вожатый шактый җитди сөйләшә иде.— Ник болай пассив син, ә?

Бу юлы инде Сәет башын аска иеп тормады, үзенең шартын әйтте дә бирде:

— Чабыш атларыгыз бармы соң сезнең? Мин үзебезнең авыл сабантуенда «Очкын»ым белән иң беренче килгән идем...

Группа башта тып-тын калды, аннары, барысы бергә күтәрелеп, дәррәү көләргә тотындылар. Сәет аларга үпкәләмәде: нишлисең бит, гомер буе Казаннан чыкмаган бу балаларның күбесе тере атны күргәне дә юктыр әле?! Ак күбәләкле кыз, көлеп туйгач:

— Син юри шулай әллә нәрсәләр таптырасың, әйеме? — дип сорап аптыратты.— Үзең аттан куркасыңдыр да әле!

Аңа башкалар кушылдылар.

— Әнә агачтан ясаган, атынып уйный торган ат бар, утыр да чап! — диештеләр.

Күңелдәгеен ачыктан-ачык әйтеп салып, көлкегә каласын уйлап бетермәгән иде шул Сәет. Барысының да сүзен тыңлап, башын аска иеп утырудан башка чарасы калмады. Әгәр тәрбияче бәхәсне башка якка борып алмаса, елап ук та җибәргән булыр иде әле ул.

Шулай да Сәеткә сүзләренең хаклыгын расларга җай табылды. Беркөнне пионерларны якынга гына урнашкан «Чулпан» колхозына алып киттеләр. Кайберәүләр яшелчәчеләргә булышты, унлап малайны бригадир абый борчак басуына илтте. Анда берничә абый комбайн керә алмый торган җирдә

борчак чаба иде. Сәет шулар янына килде. Сорап алды чалгы. Әүвәл, тикшергәндәй, чалгының йөзен кулы белән сыдырып карады. Аннары, киң генә алдырып, селтәнеп җибәрде: чаж да чож, чаж да чож! Теге малайларның күзләре ут яна!

— Сәет, кая мин дә чабыйм әле! — диләр.

Нигә бирмәсен Сәет, ул саран түгел. Бирде. Селтәнеп-селтәнеп тә карадылар. Чалгының очы бара да кадала йомшак җиргә, бара да кадала.

— Ярамый алай,— диде Сәет.— Чалгыны харап итәрсез.

Соңыннан аларны колхозчыларның кыр ашханәсендә яңа өлгергән борчак ашы белән сыйладылар. Аерылышыр алдыннан бригадир абый балаларга рәхмәт әйтте. Сәетнең исемен аерым телгә алды. «Колхозларга Сәет Шамкин кебек уңган егетләр кирәк! — диде.— Мин аны хәзер үк үз колхозыбызга алып калыр идем, ярамый, аның әле лагерьда ял итәсе бар. Аннары әти-әниләре янына кайтыр, укыр, зур үсәр. Бу колхоз аның хәтерендә озаграк сакланып калсын өчен, мин аны, атыма атландырып, бераз йөртеп киләм...»

Бригадирның сүзен ак күбәләкле кыз бүлде:

— Ул үзе дә атка атланып йөри белә.

— Чынмы?

— Әйе. Үз авылымда «Очкын»ым бар минем анда...

Бригадир елмаеп җибәрде. Сәетне күтәреп алды да алмачуар атына атландырып та куйды.

— Әйдә, чап, җаның теләгән якка, энекәш! Каушама, минем ат юаш, чыгымчылый торган гадәте юк.

Сәет басуның аргы башындагы зәңгәрләнеп күренгән урманга әллә кайчаннан кызыгып карап тора иде инде. Ат менеп алгач, ике дә уйламый, шул якка атылды.

— Я-а-а, бахбай!..

Шулай күңелле генә көн арты көн үтеп бара иде. Бер якшәмбедә лагерь халкы гөжли башлады. Әти-әниләр белән очраша торган көн икән бу. Сәет алдан ук белде: аның янына берәү дә килә алмас. Әтисенә — көтүне, әнисенә ферма сыер-

ларын ташларга ярамый. Кая ди ул сиңа! Әнисе сөйли, саву вакытын ярты сәгатькә генә соңарсаң да, сыерлар холыксызлана, сөтен киметә, ди.

Кешеләр килер көнне Сәет барыбер күзен юлдан алмады. Иртәнге ашны ашап та өлгермәгәннәр иде әле, Казан ягыннан төркем-төркем кешеләр күренә башлады. Кайсылары үз «Жигули»ларына утырып килә. Кулларында — олы сумкалар. Лагерь эчендәгеләр аларны әллә кайдан танып ала: «Әтием!», «Әнием!», «Ап-па!» — ди-ди, кычкырыша-кычкырыша каршы чабалар. Аннары алар, тәрбиячедән рөхсәт сорап, лагерь мәйданыннан чыгып, урманга китәләр, еракка...

— Менә бу — минем дус малай, энием, Сәет исемле! — Койма буена басып, очрашучыларны күзәтеп торучы Сәет сискәнеп китте. Аның янына әлеге дә баягы шул ак күбәләкле Галия әнисен алып килгән.

— Бик әйбәт, менә хәзер өчәүләп урманда йөреп килербез,— диде әни кеше.— Әйдә, Сәет, мин тәрбиячегә әйтермен.

Урманда йөреп туйгач, алар су буена төшеп утырдылар, табын кордылар. Галиянең әнисе бөтен кучтәнәчләреннән Сәеткә дә өлеш чыгара барды. Хәтта бер плитка шоколадны да икегә бүлмәкче иде.

— Кирәкми, апа,— диде Сәет.— Мин аны элек тә ашамый идем, үзе бик төче, үзеннән көйгән арпа тәме килә...

Галиянең әнисе киткәч, Сәет, бөтен группадан аерылып, палаткага керде. Берәү дә юк. Ялгызлыктан файдаланып, Сәет ак җәймә өстенә капланды. Әллә нигә күзе чыланды, борыны йомшады. Бугаздагы каты төер эреп юкка чыкканчы шулай ятты Сәет. Төшке ашка барганда каршысына Галия килеп чыкты, бәйләнә башлады.

— Тузан кергән, ахры, күзләрең кызарган, әйдә врачка! — ди.

Күзләренең ник кызарганын Сәет врачлардан яхшырак белә, авылны күрәсе килә аларның, шуңа күрә кызаралар.

Лагерь дигәннәренең бер генә яман ягы бар: соңгы көннәр бик акрын уза анда. Көтәсең кайтып китәр көнне, әй, кө-

тәсең — һаман җитми. Авылдан киткәнгә инде мең былтыр кебек. Чебиләр тавыкка әйләнеп беткәндер, каз бәбкәләре үзләре, ата каз кебек, ысылдап кала башлаганнардыр, Нурсинә дә зур кызга охшап үскәндер кебек.

...Баксаң, ул кадәр үк үзгәрешләр юк икән лә. Авыл һаман үз урынында, Нурсинәгә дә берни булмаган — гел шул кысык күзле, тузган чәчле, тешсез кечкенә кыз килеш торган. Алай да Сәет аңа лагерьга әти-әниләр килгән көнне мендәргә капланып елавын ычкындырмады. Үзе лагерьга бармаган кеше аның ул хәлен ничек аңласын! Менә үзе барса, егерме дүрт көн авылдан читтә яшәсә, сагынуның ни икәнен белер иде!..

ГАРӘП ТЕЛЕ ӨЙРӘНГӘНДӘ

Гөлия ишетелер-ишетелмәс тавыш белән кабатлады да кабатлады:

— Кыйт-тә-ти, кыйттәти сәгыйрә...

Аны читтән генә әбисе Шәмсия күзәтеп тора. Ул оныгына сүз кушарга кыймады, күңелен бик күңелсез сорау борчый иде югыйсә. Үзенчә болай юрады ул: «Сүзләре гел без укый торган догаларга охшаш. Бу да шуларны өйрәнә башлаган?! Ничек була соң инде бу: үзе пионер, комач кызыл галстук тагып йөри, үзе дин юлына кереп бара, һе?! Менә ышан син шул җаннарга! — Аннары ул уйларын башка якка борып җибәрде.— Хәер, әткәй мәрхүм әйтә торган иде, күңел түрендәге фикере кай якны хупласа, тыштан ни кылса да, башкасы исәпхисапка керми, ди торган иде. Киемең тырыс булса да, күңелең дөрес булсын...»

Гөлия Казанның 80 нче мәктәбенә авылдан килеп керде. Шәмсия әбинең ялгыз калуын белгәч, әтисе шулай кирәк тапты. Әбисенә иптәш тә, булышчы да булыр, янәсе. Шәһәр мәктәбендә укый башлады ул. Әллә ни аермасы да юк югын, тик чит телләре гарәп теле икән, авылда алар немец телен өйрәнәләр иде.

Гарәп теле дәресенең беренчесе үк Гөлиягә зур яңалык булып тоелды. Укытучы абый бу телнең бик бай икәнлеген, дөньядагы бик күп халыкларның шушы телдә аңлашуларын сөйләде. Аннары алар гарәп алфавитын өйрәнергә тотындылар. Укытучы һәр хәрефне тактага яза да исемен әйтеп куя:

— Әлиф, би, ти, си, җом...

Гөлия:

— Әнеккәй генәм! — дип кычкырып ук җибәрде.— Бу бит дога!

Гөлиягә моңарчы да гарәпчә язылган китапларны күрергә туры килгәне бар иде. Шәмсия әбисе авылга кайтканда ап-ак яулыгына төреп берничә иске китап алып кайта иде. Ул аларны бик кадерләп кенә йөртә, кеше кулы тимәстәй аулак урында гына тота. Гөлия аларга кагылырга да кыймый иде. Берсендә аңа әбисе бер дога да өйрәтте. Алдан кисәтеп куйды:

— Балам,— диде,— дөнья хәлен белеп булмый, әллә нинди бәлаләргә тап булуларың да ихтимал. Менә шундый кыен хәлләрдә калган чакта эчтән генә укый торган бер дога өйрән әле син!

Кечкенә Гөлия өйдә ялгыз калып, шомлана-нитә башласа, әбисе өйрәткән шул доганы пышылдый торган булып китте:

— Әлип-пи-ти-си...

Үзе әйтә, үзе эчтән генә уйлый иде: «Хәзер минем бу сүзләремне берәү ишетеп ала да куркыныч хәл булмыйча кала».

Кыз өйрәнгән вакытта бу аңлаешсыз сүзләрнең нинди мәгънә аңлатуын да сораган иде, тик аңа юньләп төшендереп бирмәделәр. Барысы да гел бер үк сүзне кабатлады: «Алла турында күп белүнең кирәге юк»,— диделәр. «Кая соң ул алла, ул мине ничек ишетер?» — дисәң, бөтенләй ачуланырга ук тотыналар. «Юньсез! — Шундый сорау бирәләрмени? Алла ул бер җирдә генә түгел. Ул бөтен җирдә: алда да, артта да, уңда да, сулда да, өстә дә, аста да. Бөтен җирдә берьюлы! Андый сорау башыңа кермәсен, җеннәр буташтырадыр сине? Тизрәк «әлип-пи-ти-си»еңне укы!» — диләр.

Гөлия шуннан артыгын сорамас булды. Догалар, әллә нин-

ди серле хәрефләр белән сырлап тутырылган китаплар алла бабайның кешеләргә биреп калдырган бик борынгы бүләк-истәлекләредер инде, дип үзенчә нәтиҗә ясап куйган иде инде ул. Баксаң, хикмәт анда да түгел икән. Китаптагы сүзләр дә, «әлип-пи-ти-си» дә дога түгел, әллә нинди куркынычтан саклый торган серле сүз түгел, гарәп теленең гади алфавиты икән бит! Әбиләр аны бозып өйрәткәннәр икән әле, җитмәсә! «Әлип» түгел, «әлиф» — гарәп алфавитындагы беренче хәрефнең исеме, безнең «а» хәрефе кебек; «пи» түгел, «би» — «б» хәрефе. Их, әбиләр, әбиләр! Ни генә уйлап чыгармыйлар!

Гарәп телен өйрәнә барган саен Гөлия картларның дин хакындагы күп кенә ялгыш фикерләрен ача башлады. Аларның күп кенә «изге»гә санап йөргән нәрсәләре тел белмәү галәмәте генә булуына төшенде. Авылга кайткач, Гөлия мич өстендәге иске китап-дәфтәрләрне укып караган иде — гап-гади җырлар икән. Ә бер дәфтәр — әле бабасы исән чакта ук язып барган сәүдә эшләре, гамәл дәфтәре икән ул.

Гарәп телен яхшырак өйрәнгән саен Гөлия мондый ачышларны күбрәк ясый. Бер өйрәнгәч, бу телнең искиткеч матур яңгырашына, байлыгына да соклана. Аны белгән саен тагын да күбрәк беләсе килә. Гөлия хәзер әбисенең китапларын да тәрҗемә иткәли, аңлатып-аңлатып укый. Башта аның бу шөгылен Шәмсия әби бик үк өнәп бетермәде, китапларын да тотып карарга рөхсәт итми йөрде. Көннәрдән бер көнне Гөлия бер кочак өр-яңа гарәпчә язылган китаплар күтәреп кайтып кергән иде — аптырады да калды. «Әлип-пи-ти-си» турында аңлатма биргәч тә бәхәскә кермәде. «Ала-ай!» — дип кенә куйды.

Якшәмбе көнне әбисе Гөлиягә:

— Балам, вакытың булса, мине ахирәтем Мәсрүрәләргә алып бар әле, зинһар! — диде.— Аяк асты бик тая, ялгыз юлга чыксам, таеп егылудан куркам.

— Әйдә, әби, әйдә! — диде Гөлия.— Мәсрүрә әбинең талкыш кәләвәсен бик яратам мин, чәй эчәрбез.

Барып керсәләр, түр стенага гарәпчә хәрефләр белән язылган шәмаилне [1] күреп көлеп җибәрде кыз.

Мәсрүрә апа ачуланырга да, ачуланмаска да белми уңайсызланып калды. Ахырда:

— Ярар инде, балам, минем җиһазлардан көлмә! Без — картлар инде, үзебезгә ярый,— диде.

Гөлия тиз генә аңлатырга мәҗбүр иде:

— Юк, Мәсрүрә әби! — диде.— Мин сезнең җиһазларны бик яратам, менә бу язуда гына хата киткән. Ике нокта куясы урынга берне генә төрткәннәр дә «т» хәрефе «н» хәрефенә әйләнгән, начар сүз килеп чыга язган. Гарәп теле шундый ул, бик игътибарлы булырга кирәк.

Әбиләрнең күзләре шар булды. Хуҗа әби, шәмаилне алып, карават астына яшерде, үзе сукранды:

— Кыяфәте үк тә ышанычсыз бер бәндә сатып китте аны миңа,— диде.— Үзем мин гарәп хәрефен яхшы белмим, күрше карчыгыннан күрмәкче генә алып таккан идем. Надан булу шулай итә ул, аны теләсә кем алдап йөри.

Дустының сүзләрен Шәмсия әби дә күтәреп алып китте:

— Әйтмә дә инде, Мәсрүрәкәем! — диде.— Мин әле үз баламнан, менә шушы оныгымнан шикләнеп йөрдем. Мәктәбеннән кайтып керә дә тирбәлә-тирбәлә әллә нинди сүзләр ятлый. Гел безнең догаларга охшаш сүзләр. Мәйтәм, пионер үзе, үзе дин сабагы өйрәнә түгелме соң бу? дим.

Гөлия тагын аптырый калды.

— Кайчан алай шикләндең соң син, әби? Ник үземнән сорамадың? Кайсы дәрескә әзерләнгән вакытым булды икән?

— «Кыйттәти» дә «кыйттәти» дигән идең, шунысы гына истә калган.

Кыз көлеп җибәрде.

— Ә-ә-ә! «Кыйттәти сәгыйрә, васмуха Нәмирә...». Шигырь ул, әби, «Песием кечкенә, исеме Нәмирә»,— дигән сүз. Ул шигырьне әйбәт ятлап, бишле алган идем мин.

Барысы да көлеп җибәрделәр.

---

[1] Гарәп хәрефләре белән язылган дини китаптан художестволы итеп күчерелгән өзекләр, изге урыннарның рәсемнәре.

АЧУЛАНМАСАГЫЗ?!

Трактор йөртә белүче укучыларның район күләмендәге ярышлары булачагы турында Ясминә су коенырга барган җиреннән ишетеп кайтты. Өстен-башын алмаштырды да хезмәт дәресе укытучысы Хәмит абыйларына йөгерде.

Хәмит абый яшелчәләренә су сиптереп йөри иде. Шөгыле белән тәмам мавыккан. Хатыны:

— Хәмит, тукта, әнә бер укучың килгән, синең белән сөйләшмәкче,— димәсә, Ясминәгә күтәрелеп карамаган да булыр иде.

Ясминә укытучысының соравын-фәләнен көтеп тә тормады:

— Абый, тракторчылар ярышына мине дә алып барыгыз әле! Шуңа килүем,— диде.

— Нинди ярыш турында сөйлисең син, Ясыйрова?—Хәмит абый зур эшләр турында сүз барганда гел фамилия белән генә эндәшә.— Каян ишетеп өлгердең әле?

— Сәмигуллин Хәйдәр, мин ярышка барам, дип, әллә кем булып йөри.

— Йөри бирсен!

— Минем дә барасым килә бит, абый.

— Син беләсеңме соң: безнең мәктәптә тракторчы булырга бары тик малайлар гына өйрәнде, кызларны сыер саварга өйрәттек без, дөресме?

— Хәмит Вәгыйзович! — Ясминә дә, мәктәптәгечә иттереп, рәсми төстә сөйләшә башлады.— Мин трактор йөртергә этидән өйрәндем. Безнең эти — гомере буе тракторда. Аны районда да мактап кына торалар.

— Ясыйрова! — Хәмит абыйның ачуы кабарды.— Син һаман үз туксаныңны тукыйсың. Кабатлап әйтәм: безнең мәктәптәге кыз балалар тракторчы курсын үтмәделәр.

Укытучысы белән уртак тел таба алмагач, Ясминә этисе белән сөйләшеп карарга булды. Ә ярыш үткәреләсе көнне кыз иртүк автобус тукталышына чыгып басты. Хәмит абый белән Хәйдәр дә шунда иде. Алар беравыздан:

— Кая җыенуың болай, Ясминә? — диделәр.

— Базарга. Май сатарга.

Укытучы кашын җыерды.

— Сату-алу итеп йөргәндә пионер формасы кимәсәң дә ярар иде.

Башка чакта мондый кисәтү ишетсә, Ясминә оятыннан кереп кысылыр җир тапмый интеккән булыр иде. Бу юлы исе дә китмәде.

Хәер, аңа ни дә булса әйтердәй вакыт та юк иде — автобус килде. Район үзәгенә җиткәч, шофер бөтен кешене төшерде. Хәмит абый:

— Безне райкомолга илт инде! — дигәч, тыңлады тагын. Кызның да төшми утыруын күреп алгач, Хәмит абый Ясминәгә:

— Бар, Ясыйрова, сөт-май базарына моннан якын,— диде.

Кыз селкенергә дә уйламады: «Хәйдәрнең ничек эшләвен карап торырмын, ичмасам!» — диде дә утыра бирде.

Райкомол янында алар башка мәктәпләрдән җыелган балалар белән кушылдылар. Аларның барсын бер машинага утыртып район үзәге читендәге басуга алып киттеләр. Бу юлга кузгалыр алдыннан Хәмит абый кабат:

— Ясыйрова, син анда нишләмәкче буласың, ә? — дип, бик усалланып сорады.— Сатасы майларың эреп агар, әниеңә ни җавап бирерсең?

Ясминә кинәт кенә тавышын үзгәртеп җибәрде, еламсырап:

— Ачуланмагыз инде, абый! — диде.— Хәйдәрне генә карап торырмын.

Укытучы шунда гына кызның кулында бернинди дә сөтмай савытының булмавын абайлап алды.

— Маең кайда соң синең?

— Әй, абый, бәйләнмәгез инде!

Укытучы Хәмит абый аптырап калды.

— Ясыйрова! Базарда сатасы маең кайда синең, ә? Әниең күзенә ничек кайтып күренерсең?

— Абый-канатым! — Ясминә үз авылларының кешеләренә генә хас булганча, «канатым» сүзен кыстыра-кыстыра ялварырга тотынды.— Мине әни түгел, әти җибәрде монда. Ачуланмагыз инде, абый!

— Ник җибәрде?

— Бүгенге ярыш башлыгы Хөрмәтуллин абыйга менә шушы язуны бирергә кушты.

— Эһһем-эһ-эм! — Укытучы, «Хөрмәтуллин» фамилиясен ишеткәч, сүрелә төште.— Кая, ни дип язды икән? Укып карыйк!

Тик конвертның ябыштырылганлыгын күргәч, ул үз уеннан кире кайтты. «Син ул абыеңны таныйсыңмы соң?» — дип кенә сорады. «Юк шул»,— диде Ясминә.

— Әнә ак эшләпәле. Иплэп кенә сөйләш!

Әтисе, хатны Хөрмәтуллинга тапшыргач, бераз көтеп торырга кушкан иде. Ясминә конвертны сузды да, ул абыйның күзенә күтәрелеп карарга да кыймыйча, башын аска иеп кенә тора бирде. Хәер, әллә ни озак көтәргә туры килмәде. Абый кеше хатка күз йөгертеп кенә алды да:

— Бу — синмени, Ясминә Әгъләметдиновна!? — диде. Аннан: — Ясыйрова иптәш «Беларусь»та ярышырга атлыгып тора ди.

Хәмит абый: «Ә? Ничек?» — дип ычкындыруын сизми дә калды. Ярый әле, Хөрмәтуллин абый аны ишетеп өлгермәде. Ул һаман үзенекен сөйләвендә булды:

— Әгъләметдин Ясыйров — районыбызның иң алдынгы тракторчысы, бу ярышта аның кызы да катнашу — май өстенә бал!

Район күләмендәге ярышны Ясминә чаңгычылар узышуы итебрәк күз алдына китерә иде. Ялгышкан икән. Бернинди охшашлык та юк. Монда башта тантаналы сөйләүләр булды. Иң алдан Хөрмәтуллин абый чыкты. Аңа башкалар кушылды. Ясминә бу сөйләшүләрдән гомер буе күңел түрендә саклардай сүзләр отып калды: тракторчы һөнәре бик кирәкле, бик игелекле эш икән. Бу фикер кызның уйларын еракларга алып китте. Җирән чәчле бер апа килеп, аны үз яннарына чакырмаса, ул әле хыялларыннан тиз генә арына да алмас иде.

— Чыпчыклы мәктәбе укучысы Ясыйрова!

Хәрби команда кебегрәк яңгыраган бу сорауга Ясминә:

— Мин! — дип горур җавап кайтарды.

— Әзерлән! Вакыт җитте.

...Ясминә үз мәктәпләренең өр-яңа «Беларусь»ында игенчегә кирәкле эшләрне башкарып күрсәтергә тиеш иде. Яңа тракторның төзелешендә, этисенең иске «Беларусь»ына караганда, кайбер үзгәлекләр дә бар. Ясминә моны бик яхшы белә. Ник дисәң, Хәйдәр мәктәп участогын сөргән чакта, башкалар күрмәгән арада, кыз трактор кабинасына кереп утырган иде. «Хәйдәр абыем-канатым! Бер генә әйләним әле!» — дип, инәлә-инәлә егетне күндергән иде. Кайбер тоткаларның урыны үзгәртелүне искә алмаганда, этисенекеннән әллә ни аерылмый иде бу яңа трактор.

Их, эшнең болай зур ярышка барып тоташасын белсә, Ясминә бу зәңгәр трактордан төшмәгән дә булыр иде дә бит!..

Ярыш мәйданын сискәндереп кыска-кыска командалар яңгырый башлады. Ясминәне ялкын урап алгандай булды. Каушау да, җанның әллә кайларга ашкынуы да бар сыман. Ярый әле, янга Хәмит абый килеп баскан.

— Каушама, сеңел! — диде ул. Ясминәнең бу укытучыдан гомердә дә мондый сүз ишеткәне юк иде.—Әгәр бүләкле урыннарга ук чыгарга ниятләмәсәң, әйдә, бергә утырыйк, ярышның

шундый шарты да бар. Ал мине дә кабинаңа! Ярышта катнашуың үзе үк бик мактаулы күренеш.

Ясминә ут белән су арасында калды. «Нишләргә соң? Нишләргә? Җиңүчеләр сафыннан үз ихтыярың белән үк баш тартыргамы, әллә, тәвәккәлләп, өр-яңа тракторга япа-ялгыз менеп кунакларгамы?»

— Ашыкма! Уйла, сеңел! — диде укытучы.— Сезгә әле тракторны карарга, иркенләп уйларга вакыт бирелде.

Ул үзе шулай сөйләнә, үзе тракторны да караштыра, кырт борылып читкә китеп бармый. Ясминәнең каушавы кими төште. Сораулы уйлары бары бер йомгакка укмашып, фикере яктырып китте.

— Ачуланмасагыз, үзем генә утырыйм әле, абый!

— Ярый-ярый! — Ни гаҗәп, укытучы монда Ясминәне гел хуплап кына тора.— Хәерле сәгатьтә, сеңел!

Соңгы команданы бирделәр. Шуннан калганын Ясминә ишетмәде дә, күрмәде дә. Кызның ни бар белгәне, көч-куәте, бөтен зиһене мәктәпнең зәп-зәңгәр тракторы кабинасындагы приборларга юнәлеп калды. Башта барысы да җайлы барды. Әйбәт, бик шәп трактор бу! Тиз кабынды, шунда ук кузгалып та китте. Тавышы да тигез, көйле, күңелле бер җыр диярсең! Аның җанга ятышлы шул тавышы Ясминәне тәмам тынычландырды да инде. Көч сынашучыларның шактый артта калуын чамалаган кыз кабина тәрәзәсе аша еракка ук карап бара башлады. Алда, томанланып, ап-ак каеннар сафы күренә. Тракторчы кызлар шул каеннар янына барып җитәргә тиешләр. Бу юлда аларның машинаны йөртү, бора белү, яңа эзгә чыгару осталыгы сынала. Әйдә, тикшерә бирсеннәр: Ясминәнең аларда гаме юк. Юк, трактор гына түгел бу, ә корычтан коелган канатлы ат бу! Ясминә шул аргамакны үзенә буйсындырып алган да киләчәккә оча! Аңа алга, бары тик алга бару гына кирәк. Мөмкин кадәр тизрәк, ыспайрак, матуррак барырга тиеш ул. Зәңгәр трактор исә бу шартларның барысына да «кырт» иттереп җавап бирә!

Ясминә шатлыклы хисләр тәэсирендә онытылып китә яз-

ды. Хыял дәрьясына чумды ул. Әйтерсең лә аның кечкенә алсу кулларында гади трактор руле генә түгел, гүя кыз галәм чиксезлегенә үк чыккан да йөзепме-йөзә! Күк гөмбәзенә генә күз сал син! Аның бөтен җетелеге, барлык яктылык көче, көлтә-көлтә нурлары— барысы да Ясминәне хуплый, анда-санда таркалган ак болыт кисәкләрен кулъяулык итеп болгый-болгый, тракторчы кызны озата бара. Алдагы яп-яшь каеннар тезмәсе дә... Бәрәкәт!

Ни булды соң әле бу? Ясминә хур була язды бит! Нәкъ әнә шул каеннар янына җиткәч, кырт борылырга, артка тагылган сабаннарны җиргә батырырга кирәк ләбаса!

...Ясминә җиңүчеләр басмасына барыбер менде. Дөрес, беренче баскыч аңа эләкмәде, Хөрмәтуллин агай, бөтен кешегә дә аңлашылырлык иттереп, өздереп әйтте:

— Кызлар арасындагы икенче урынны, бик лаеклы рәвештә, Чыпчыклы мәктәбе укучысы Ясминә Әгъләметдин кызы Ясыйрова яулап алды! — диде.— Котлыйбыз!

Ул «котлау» дигәннәренә чыдап кына тор икән. Иң әүвәл бөтен дөньяны яңгыратып кул чабалар, аннары иң өстенә киң ефәк тасма тагып куялар. Анысына җиңүче икәнлегең язылган. Муеныңа ефәк бауга кертелгән зур тәңкә-медаль кидерәләр. Ул гынамы?! Бер кочак чәчәк тоттыралар, кулыңны кысалар...

Арада Хәмит абыйдан да артыграк шатланган кеше, мөгаен, булмагандыр. Ул әле Хәйдәр янына килә, аны районның укучы малайлары арасында беренче урынны алуы белән котлый.

— Булдырдың, Сәмигуллин! — ди.— Акладың ышанычны!

Аннары Ясминәгә тутырып карый. Аңа ни әйтергә дә белми, аптырабрак тора: «Карале, Ясминә — акыллым, син ничек болай булдыра алдың соң? — ди.— Минем башка сыймый әле...»

Кызның үзе өчен бу хәлләрнең башка сыймаслык берние дә юк. Укытучы абыйсыннан да яшереп-нитеп торырга теләмәде ул.

— Бу этине яратканга килеп чыкты инде, абый,— диде.— Этинең бөтен кайгысы — безнең өйдә малайлар булмау. Ачуы чыккан саен гел бер сүзне кабатлый: «Иһ-ма, тракторны кемгә калдырырмын соң мин, ә?» — ди. Мине өйрәтте өйрәтүен, үзе барыбер ышанып җитми әле.

Тыгыз җиргә — тана башы, сүзгә Хәйдәр кысылды.

— Алай этиеңне бик шатландырырга да теләгәч, сиңа беренчелек кирәк иде инде,— ди.— Теге ике метр җиреңне чи калдырмасаң, беренче була идең. Ник сабаныңны төшерми тордың, ә?

Ясминәнең керфекләре аска иелде, йөзе кура җиләге төсенә керде, үтә күренердәй нечкә борын яфраклары еш-еш кабарынгаларга тотынды. Тегеләр дә, кызны үпкәләтүләреннән куркып, бүтән ләм-мим эндәшмәс булдылар. Бераз вакыт өчесе дә тып-тын торды. Аннары кыз елмайгандай итте, ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

— Минем бу яңа тракторның сабанын күтәреп-төшереп көйли торган тоткасына буем җитми икән бит, абый,— диде.— Сузылам, сузылам, тота алмыйм, трактор бара да бара. Котым очып, урынымнан сикереп төштем дә ике куллап эләктереп алдым үзен. Секунд эчендә генә булган кебек иде, ике метр китеп тә өлгерелгән.

Хәйдәр маңгаен төйгечләргә тотынды:

— Их! — ди.—Теге чакта ук ул рычагка синең буй җитмәгәнне күреп тордым бит мин! Анда үзем булышкан идем, шуны сиңа әйтергә онытканмын...

Укытучы абый да уйга калды.

— Монда минем дә гаеп бар, укучылар,— диде.— Әгәр Ясминә килеп сораугa, бергәләшеп киңәшкән булсак, шул тоткага бер җайланма көйләп куяр идек...— Ул булып узган тантана шатлыгын кабат исенә төшерде бугай, елмаеп җибәрде.—Менә шул якларын да искә алып әзерләнсәк, безнең Ясминә киләчәк ярышларда, һичшиксез, беренчелеккә чыгачак!

15 тиен